## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

**1 статья. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең исеме һәм хокукый статусы**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге авыл җирлеге статусына ия.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба текст буенча – Җирлек).

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы составына керә.

**2 статья. Җирлекнең территориаль төзелеше**

1. Җирлек территориясе составына Биектау тимер юл станциясе, Березовка, Яңа Поселок, «Каменка» санаторие, Урманче, Киндерле тимер юл разъезды бистәләре керә.

2. Җирлекнең административ үзәге - Биектау тимер юл станциясе бистәсе торак пункты.

3. Җирлек чикләре «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән.

4. Җирлек территориясе составына милек формасына һәм максатчан билгеләнешенә бәйсез рәвештә җирләр керә.

5. Җирлекнең чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

**3 статья. Җирлекнең рәсми символлары**

1. Җирлек, федераль законнар һәм геральдик кагыйдәләр нигезендә, аның тарихи, мәдәни, милли һәм башка төр җирле традицияләрен һәм үзенчәлекләрен чагылдырган үз рәсми символларын булдырырга хокуклы.

2. Символларны раслау, аларның тасвирламасы, аларны рәсми рәвештә куллану тәртибе җирлек Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

**4 статья. Җирлектә халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда хокукы**

1. Җирлектә җирле үзидарә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашулар, башка төр ихтыяри теләк белдерү формаларында, шулай ук әлеге Устав белән каралган, сайлана торган һәм башка төр җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне женесе, расасы, милләте, теле, килеп чыгышы, милке, биләгән вазыйфасы, дингә мөнәсәбәте, карашлары, иҗтимагый берләшмәләргә катнашы булу-булмавына бәйсез рәвештә турыдан-туры да, шулай ук вәкилләр аша да тормышка ашыруда тигез хокуклы.

Җирлек территориясендә даими рәвештә, яисә күпчелек яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә билгеләнгән хокукларга ия.

3. Гражданнар җирле үзидарә органнарына һәм Җирлекнең җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары һәрбер кешегә аның ирекләренә һәм хокукларына турыдан-туры кагылышы булган документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук гражданнарга Җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка төр тулы мәгълүмат алуны, закон тарафыннан башка очраклар каралмаса, тәэмин итәргә тиеш.

5. Җирлекнең җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәмендә яки башка чаралар белән, Җирлек үсешенең әһәмиятле мәсьәләләре һәм аның аерым территорияләре, халыкка төрле төр хезмәт күрсәтүче җәмәгать транспорты, торак-коммуналь хуҗалык, социаль-мәдәни һәм башка учреждениеләр һәм хезмәтләр күрсәтү челтәре үсешен, социаль льготалар, җәмәгать тәртибен саклау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында гражданнарга һәрдаим хәбәр итеп торалар.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр аларның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судта шикаять белдерергә хокуклы.

**5 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасы**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасына әлеге Устав нигезендә оештырылган Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты, Җирлекнең Ревизия комиссиясе һәм башка җирле үзидарә органнары керә.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасына үзгәрешләр кертү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

**6 статья. Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләре**

1. Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә керәләр:

1) Җирлекнең бюджет проектын төзү һәм карау, җирлекнең бюджет проектын раслау һәм үтәү, аны үтәү буенча контрольне гамәлгә ашыру, Җирлекнең бюджет проекты үтәлеше буенча хисап төзү һәм раслау;

2) җирле салымнар һәм җирлек җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

3) Җирлекнең муниципаль милкендәге милеккә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын саклау буенча беренчел чаралар белән тәэмин итү;

5) Җирлектә яшәүче халыкка элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру;

6) ял вакытын оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) Җирлекнең архив фондларын булдыру;

9) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, Җирлек территориясен әлеге кагыйдәләр нигезендә төзекләндерүне оештыру;

10) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлегенә шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

16) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ;

18) Җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының милләтара һәм динара килешүен ныгытуга, телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) Җирлек халкының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, төзекләндерүне оештыру .

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән аларга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Биектау муниципаль районы бюджетына Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабыннан тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

**7 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүдә хокуклары**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Җирлек музейлары булдыру;

2) Җирлектә нотариус булмаган очракта, законнар белән билгеләнгән тәртиптә, нотариаль гамәлләр башкару;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

4) Җирлек территориясендә милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендәге милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге гамәлләрне тормышка ашыруга ярдәм күрсәтүгә;

6) Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең мобилизацион әзерлеге буенча чаралар оештыру һәм тәэмин итү;

7) муниципаль янгыннан саклау хезмәте оештыру;

8) туризм үсешенә шартлар тудыру;

9) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

10) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

11) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарыннан найм шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан гражданнарга торак урыннары бирү.

12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

14) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культура һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтү;

15) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән аларга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Биектау муниципаль районы бюджетына Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

**8 статья. Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы**

Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы җирле үзидарә турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тормышка ашырыла.

**9 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре**

Җирлекнең җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгеләр белән тормышка ашырыла:

1) Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Җирлекнең социаль-икътисади үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;

2) Җирлекнең җирле үзидарә органнары белән дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яисә вакытлыча координация, консультация, киңәш бирү һәм башка эш органнары булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Җирлек Советының закон чыгару инициативасы;

5) законнарда билгеләнгән үзара хезмәттәшлекнең башка формалары.

**10 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу**

Муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне дә кертеп, Җирлектә муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәткәрнең статусын, муниципаль хезмәтне үтү шартлары һәм тәртибе билгеләү, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 нче июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

## II бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУЫ ФОРМАЛАРЫ

**11 статья. Җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы формалары**

Җирлек халкы җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыра һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда түбәндәге формаларда катнашалар:

1) җирле референдум;

2) муниципаль сайлаулар;

3) Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлап куйган органын, Җирлек Башлыгын кире кайтару буенча тавыш бирү;

4) Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

5) гражданнарның хокук чыгару инициативасы;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә;

7) гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар;

8) гражданнар җыелышы;

9) гражданнар конференциясе (делегатлар җыены);

10) гражданнар җыены;

11) гражданнарны сораштыру;

12) җирле әһәмияткә ия булган аеруча мөһим сораулар буенча халыкның фикер алышуы;

13) иҗтимагый (консультатив) советлар оештыру;

14) гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүе;

15) Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән башка төр формалар.

**12 статья. Җирле референдум**

1. Җирле референдум җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне турыдан-туры халык тарафыннан хәл итү максатыннан, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә уздырыла.

2. Җирле референдум "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, Җирлекнең бөтен территориясендә уздырыла.

3. Җирле референдумда катнашырга яшәү урыннары Җирлек чикләрендә булган Россия Федерациясе гражданнары хокуклы. Җирлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре нигезендә һәм закон белән билгеләнгән тәртиптә, җирле референдумда Россия Федерациясе гражданнары кебек үк катнашалар. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры үз теләген яшерен тавыш бирү нигезендә белдереп катнашалар.

4. Җирле референдум уздыру турында карар Җирлек Советы тарафыннан түбәндәгеләр инициативасы буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукына ия гражданнар;

2) уставлары сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашу мөмкинлеген күздә тоткан һәм федераль закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәү узган сайлау оешмасы, башка төр иҗтимагый берләшмәләр;

3) Җирлек Советы һәм Җирлек башлыгының бергә алга чыгарган инициативасы белән.

5. Әлеге статьяның 4 булеге 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка төр иҗтимагый берләшмәләр инициативасы белән җирле референдум уздыруның шарты булып әлеге инициативаны яклап җирлек территориясендә теркәлгән җирле референдумда катнашучылар саныннан биш проценты күләмендә, ләкин 25 имзадан да ким булмаган күләмдә имзалар җыю тора.

6. Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгының бергә алга чыгарган референдум уздыру турында инициативасы Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе хокукый актлары нигезендә рәсмиләштерелә.

7. Җирлек Советы җирле референдумны Җирлек Советына җирле референдум уздыру турында документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгели.

Җирле референдум Җирлек советы тарафыннан каралган срокларда билгеләнмәгән очракта, референдум гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, Җирлек башлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясенең яисә Биектау муниципаль районы прокурорының мөрәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдум Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла, ә аны уздыруны тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле референдумны үткәрүне тәэмин итү суд тарафыннан йөкләнгән башка орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

9. Җирле референдумда кабул ителгән карар Җирлек территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органы, аларның вазыйфаи затлары яки Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

10. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләр бүлешү нигезендә тәэмин итәләр.

11. Җирле референдум уздыру турындагы карарга, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга карата гражданнар, җирле үзидарә органнары, Биектау муниципаль районы прокуроры, федераль закон белән дәүләт хакимияте органнары тарафыннан вәкаләт бирелгән дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

**13 статья. Муниципаль сайлаулар**

1. Җирлектә муниципаль сайлаулар, Совет депутатларын сайлау максатыннан, гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә, яшерен тавыш бирү юлы белән тормышка ашырыла.

2. Җирлек Советы депутаты булып сайлау көненә 18 яше тулган, сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданины сайлана ала.

3. Муниципаль сайлауларны Җирлек Советы билгели. Муниципаль сайлауларны билгеләү турында карар тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән дә иртәрәк булмаган һәм 80 көннән дә соңрак булмаган срокта кабул ителергә тиеш. Күрсәтелгән карар массакүләм мәгълүмат чараларында ул кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, муниципаль сайлаулар Җирлекнең сайлау комиссиясе яки суд тарафыннан билгеләнә.

4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм оештыру, сайлау комиссияләренә аларны компетенцияләре чикләрендә йөкләнәләр.

5. Җирлек Советы депутатларын сайлаулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

6. Җирлек Советы депутатлары бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлау округына сайлаучылар вәкилләренең уртача нормасы нигезендә сайланалар.

7. Бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган дип, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын алган теркәлгән кандидат санала.

Әгәр дә Җирлек Советы депутатларны сайлауда бер мандатлы сайлау округында тавыш бирү бер генә кандидат буенча уздырылса, кандидат тавыш бирүчеләрнең 50 процент тавышыннан да ким тавыш алмаган очракта сайланган дип санала. Теркәлгән кандидатлар арасында сайлаучыларның бертигез тавышын алган очракта, алдан теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

8. Җирлек Советы депутатларын сайлау нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**14 статья. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, Җирлек башлыгын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү**

1. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Җирлек башлыгы, сайлаучылар тарафыннан гамәлдәге законнарда һәм әлеге Уставта билгеләнгән нигездә һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алынырга мөмкин.

2. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, Җирлек башлыгын кире чакыртып алу нигезләре булып, депутатның аңа карата сайлаучыларның ышанычын шик астында куючы һәм депутат йөкләмәләрен, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы яки Җирлек Башлыгы йөкләмәләрен үтәмәүдә чагылыш тапкан, депутат статусына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы яисә Җирлек башлыгы статусына туры килми торган гамәлләр кылу, һәм башка Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозулар, суд тәртибендә расланган конкрет хокукка каршы карарлары яисә гамәлләре (гамәл) тора.

3. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча уздырыла.

4. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту тавыш бирү уздыру инициативасын алга чыгару һәм гражданнарның аны яклап имзалар җыю өчен, муниципаль сайлауларда катнашу хокукы булган 10 кешедән дә ким булмаган инициатив төркем оештырыла.

5. Инициатив төркем Җирлекнең Сайлау комиссиясенә инициатив төркемне теркәү турында үтенеч язуы белән мөрәҗәгать итә. Инициатив төркемнең үтенеч язуында Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту буенча, аны кире чакыртуга нигез булып торган хокукка каршы килә торган конкрет карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмавы), инициатив төркемнең һәрбер әгъзасының яисә аның исеменнән Җирлек территориясендә эшләр башкарырга вәкиллекле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне һәм урыны, паспортының яисә паспортын алыштыручы башка төр документының сериясе, номеры һәм бирелү вакыты, аны биргән органның исеме һәм коды күрсәтелергә, шулай ук яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Инициатив төркемнең үтенеч язуы барлык күрсәтелгән төркем әгъзалары тарафыннан имзаланырга тиеш. Үтенеч язуына депутатның күрсәтелгән хокукка каршы карарлар яки гамәлләр (гамәл кылмау) расланган суд карары беркетелергә тиешле.

6. Инициатив төркемне теркәү, Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту буенча тавыш бирү инициативасын яклап имзалар җыю, җыелган имзаларны тикшерү җирле референдум уздыру өчен билгеләнгән закон тәртибендә тормышка ашырыла.

7. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту буенча тавыш бирү Җирлек Советы белән билгеләнә һәм җирле референдум уздыру өчен билгеләнгән законнар тәртибендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган үзенчәлекләрне истә тотып уздырыла.

8. Инициатив төркемнең Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакырту буенча тавыш бирү турында үтенеч язуын Җирлекнең Сайлау комиссиясе белән каралган вакытта, тиешле депутат, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасы, Җирлек Башлыгы, аны кире чакырту буенча алга чыгарыла торган нигезләр сыйфатындагы хәлләр буенча аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тәкъдим итәргә хокуклы. Күрсәтелгән депутат, җирле үзидарә сайлаулы органының әгъзасы, Җирлек Башлыгы алдан, Сайлау комиссиясе, Җирлек Советы утырышы уздырганчыга кадәр өч көн алдан, аны уздыруның вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.

9. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы, Җирлекнең Башлыгы, кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда, чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган хәлләр уңаеннан сайлаучыларга аңлатмалар бирү максатларында инициатив төркем белән бертигез нигезләрдә агитация алып бару хокукына ия.

10. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Җирлек башлыгы, чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның яртысыннан ким булмаган кадәре тавыш бирсә, чакыртып алынган дип санала.

11. Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, Җирлек башлыгын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы

Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

12. Җирлекнең Сайлау комиссиясе кире чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын рәсми рәвештә чыгарганнан соң биш көн эчендә инициатив төркемгә, Җирлек Советына һәм Җирлек Советының тиешле депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Җирлек Башлыгына чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында язма рәвештә хәбәр итә.

**15 статья. Җирлекнең чикләрне үзгәртү, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп коруга халыкның ризалыгын алу максатыннан уздырыла.

2. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү бөтен Җирлек территориясендә уздырыла, яки аның территориясенең аерым өлешләрендә "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон билгеләгән очракта уздырыла.

3. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Җирлек Советы тарафыннан, "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

4. Җирлек чикләрен үзгәртү, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр сайлау хокукына ия Җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге яисә Җирлекнең бер өлеше катнашса, узган дип санала. Җирлек чикләрен үзгәртүгә, Җирлекне үзгәртеп коруга, күрсәтелгән үзгәрешләр өчен тавыш бирүдә катнашкан Җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге яисә җирлекнең бер өлеше тавыш биргән булса, халыкның ризалыгы алынган дип санала.

5. Җирлекнең чикләрен үзгәртү һәм Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**16 статья. Гражданнарның законнар чыгару инициативасы**

1. Гражданнар әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә законнар чыгару инициативасына хокуклы.

2. Закон чыгару инициативасы белән Җирлектә яшәүчеләрнең 2 процентыннан ким булмаган күләмендә сайлау хокукына ия булган гражданнар төркеме чыгарга мөмкин.

3. Закон чыгару инициативасын гамәлгә ашыру максатларында гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

- гражданнарның яшәү (эшләү) урыны буенча җыелышларын һәм закон чыгару инициативасы белән чыгу, фикер алышу буенча башка күмәк чараларны оештырырга һәм уздырырга;
- закон чыгару инициативасы белән чыгуны яклап имзалар җыю инициатив төркемен оештыру;
- законга каршы килмәгән юллар белән закон чыгару инициативасы белән чыгуны яклап Җирлектә имзалар җыюны оештыру һәм агитация уздыру.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гражданнарга закон чыгару инициативасы белән чыгуны тормышка ашыруда булышлык күрсәтергә тиеш.

5. Гражданнарның закон чыгару инициативасы белән чыгуны тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты Җирлек Советының ачык утырышында яки Җирлек башлыгы тарафыннан, аларның әлеге Уставта билгеләнгән компетенцияләре нигезендә, документ кертелгәннән соң, өч ай дәвамында мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.

6. Гражданнарның закон чыгару инициативасы белән чыгуны тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты каралган вакытта гражданнарның инициатив төркеме вәкилләренә үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

7. Гражданнарның закон чыгару инициативасы белән чыгуны тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы Җирлек Советы регламенты, Җирлек Башлыгы норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә.

8. Гражданнарның закон чыгару инициативасы белән чыгуны тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән дәлилләнгән карар язмача рәсми рәвештә аны керткән гражданнарның инициатив төркеменә җиткерелергә тиеш.

**17 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә**

1. Җирлектә территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан җыелышлар һәм гражданнар конференцияләре уздыру, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары оештыру ярдәмендә тормышка ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яшәүче түбәндәге территория чикләрендә тормышка ашырылырга мөмкин: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайоны; җирлек булып саналмаган авыл җирлегендәге торак пункт; гражданнар яшәүче башка территорияләр.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылучы территория чикләре әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылган территория башка андый территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә аның уставы кысаларында юридик зат була ала һәм коммерцияле булмаган оешманың оештыру-хокук формасында дәүләт теркәвен узарга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнә:

1) ул гамәлгә ашырылган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максаты, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының формалашу тәртибе, вәкаләтләре туктатылу, хокуклары һәм бурычлары, органнарының вәкаләтлелек вакыты;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук әлеге мөлкәтне һәм финанс чараларын куллану һәм эш алып бару тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең туктатылу тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, конференцияләр аның уставына туры китереп чакырыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, тиешле территориянең уналты яше тулган халкының өчтән береннән ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның конференциясе аңарда тиешле территориянең уналты яше тулган халкының өчтән береннән ким булмаган өлешен тәкъдим итүче гражданнар җыелышында сайланган делегатларның өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференциясенең аерым вәкаләтләренә керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын булдыру;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары сайлап кую;

4) территориаль иҗтимагый үзидарәнең төп эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәр һәм чыгымнар сметасын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турында хисапларны карау һәм раслау.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен тәкъдим итә;

2) гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) әлеге территорияне карап тоту, төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген күрсәтелгән гражданнар акчалары исәбеннән дә, Җирлекнең Башкарма комитеты белән шартнамә нигезендә Җирлек бюджеты акчаларын кулланып та гамәлгә ашырырга мөмкин;

4) җирле үзидарә органнарына (Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы һәм Җирлек Башкарма комитеты) әлеге органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле, компетенцияләренә күрсәтелгән актларны кабул итү кертелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру, җирле бюджеттан тиешле акчаны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

**18 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру максатыннан халык, Җирлекнең җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставы проектын эшләүне тормышка ашыручы һәм бу территориаль иҗтимагый үзидарә аның чикләрендә тормышка ашырылачак территориядә яшәүче халык җыелышы чакыруны оештыручы инициатив төркем оеша.

2. Гражданнар җыелышы Җирлекнең тиешле территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләр буенча Җирлек Советында гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә Җирлек Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставы теркәлгән вакыттан оешкан дип санала.

**19 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан җирлек Башлыгына тапшырыла:

1) гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гариза;

2) һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне һәм урыны, аны биргән органның исемен яки кодын күрсәтеп, паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, шулай ук һәр вәкилнең тору урыны адресы күрсәтелеп территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы беркетмәсе;

3) ике нөсхәдә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы.

2. Әлеге статьяның 1 нче пунктында күрсәтелгән документлардан кала, башка документларны таләп итү рөхсәт ителми.

Вәкаләтле вәкилгә, исемлеген һәм аларны алу вакытын күрсәтеп, документларны алу турында расписка бирелә.

3. Җирлек Башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү турында документлар кергән көннән соң ике атна эчендә аны алдан карап чыгуны һәм уставны теркәү яки аны теркәүне кире кагу турында Җирлек Советының карар проектын әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын алдан карап чыгуда һәм киңәш бирү тавышы хокукы белән җирлек Советы утырышында катнашырга хокуклы.

5. Җирлек Советы территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү яки аны теркәүне кире кагу турында карарны әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән документларны Җирлек Башлыгы алган көннән соң 30 көн эчендә карар кабул итә. Уставны теркәүдән баш тарту дәлилләнергә тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нормаларының Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Җирлек Уставы, башка муниципаль хокукый актлары белән каршылыклы булуы тора.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру максатка ярашлы булмавы турындагы дәлилләр буенча территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

8. Җирлек Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү мәсьәләсе буенча кабул ителгән дәлилләнгән карар өч көн эчендә язмача формада рәсми рәвештә гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә (вәкаләтле вәкилләренә) җиткерелергә тиеш.

9. Җирлек Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставын теркәү карары кабул ителгән очракта уставның бер нөсхәсе, аны теркәү турында билге белән, гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә бирелә, ә икенче нөсхәсе Җирлек Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру уставына кертелгән үзгәрешләр Җирлек Советы тарафыннан әлеге статья белән билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны теркәгән көннән үз көченә керә.

**20 статья. Авыл торак пункты старостасы**

1. Авыл җирлегендә урнашкан авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнарының һәм авыл торак пунктында яшәүчеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен авыл торак пунктының старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пунктының старостасы авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча шушы авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия затлар арасыннан, составына әлеге авыл торак пункты кергән Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазифасын башкаручы, дәүләт граждан хезмәтен башкаручы, муниципаль вазифа һәм муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы шәхес була алмый, җирле үзидарә органнары белән хезмәт бәйләнешләрендә һәм алар белән башка турыдан-туры бәйләнештә була алмый.

Татарстан Республикасы законы нигезендә, тарихи һәм башка җирле традицияләрне истә тотып, авыл торак пункты старостасы вазыйфасының башка исеме билгеләнергә мөмкин.

4. Авыл торак пункты старостасы итеп түбәндәге затлар билгеләнә алмый:

1) дәүләт вазифасын башкаручы, дәүләт граждан хезмәтен башкаручы, муниципаль вазыйфа һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын башкаручы;

2) суд тарафыннан эшкә яраксыз яки чикле эшкә яраклы дип табылучы;

3) ябылмаган яки алынмаган суд хөкеме булса.

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтле вакыты җирлек уставы белән билгеләнә һәм ике елдан да ким һәм биш елдан да озаграк була алмый.

Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре вакытыннан алда авыл торак пунктында яшәүче гражданнар җыены тәкъдиме белән аның составына әлеге авыл торак пункты кергән Җирлек Советы карары буенча, шулай ук "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 бүлекнең 1-7 пунктларында билгеләнгән очракларда туктатыла.

6. Авыл торак пункты старостасы аңа йөкләнгән мәсьәләләрне хәл итү өчен:

1) авыл торак пунктында җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне чишү буенча җирле үзидарә органнары белән, муниципаль предприятие һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән хезмәттәшлек итә, шул исәптән гражданнар җыенында, җыелышларда, конференцияләрдә катнашу юлы белән, мондый чараларның нәтиҗәләре буенча, шул исәптән муниципаль хокук актлары итеп рәсмиләштерелгән, җирле үзидарә органнары тарафыннан һичшиксез карап чыгарга тиешле мөрәҗәгатьләрне һәм тәкъдимнәрне җибәрә;

3) авыл торак пунктында яшәүчеләргә җирле үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча хәбәрләр җиткерә, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълуматларны аларга җиткерүдә булышлык итә;

4) җирле үзидарә органнарына халык алдында тыңлаулар һәм җәмәгать тыңлауларын оештыруда һәм үткәрүдә, авыл торак пунктында аларның нәтиҗәләрен халыкка җиткерүдә булышлык итә;

5) әлеге Устав һәм (яисә) Җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны Татарстан Республикасы законы нигезендә гамәлгә ашыра.

7. Авыл торак пункты старостасының эшчәнлеге һәм статусының башка мәсьәләләре гарантияләре әлеге Устав һәм (яки) Татарстан Республикасы законы нигезендә Җирлек Советы норматив хокукый акты белән билгеләнә.

**21 статья. Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулары**

1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектлары буенча фикер алышулар өчен Җирлек халкы катнашында Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы тарафыннан ачык тыңлаулар уздырылырга мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар халык, Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы инициативасы белән уздырыла.

Халык һәм Җирлек Советы инициативасы узучы гавами тыңлаулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә, Җирлек Башлыгы инициативасы белән узучы - Җирлек Башлыгы тарафыннан.

3. Гавами тыңлауларга кертелергә тиешле:

1) Устав проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренә тәңгәл китерү рәвешендә, әлеге Уставны тиешле норматив хокукый актларга туры китерү максатында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) Җирлек бюджеты проекты һәм аның аның үтәлеше турында хисап;

3) Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;

4) Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябренәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен җирлек халкының ризалыгын алу тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыены белән таләп ителгән очраклардан тыш.

4. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карарны Җирлекнең тиешле органы яисә вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проектын карау көненә 20 көннән дә соңга калмыйча, гамәлдәге законнарда башкасы каралмаса, кабул итәргә тиеш.

5. Гавами тыңлаулар, аларны уздыруның вакытын һәм урынын күрсәтеп, уздыру турындагы карар һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, әгәр законнарда башкасы каралмаса, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар бастырылган көннән башлап уздырылган көнгә кадәр Җирлек халкы Җирлек Башлыгына язма рәвештә гавами тыңлауларга кертелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, шул исәптән гавами тыңлауларга кертелүче муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча төзәтмәләр һәм башка төр тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Җирлек Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләр гавами тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.

7. Гавами тыңлаулар, гамәлдәге законнарда башкасы каралмаса, муниципаль норматив хокукый акт проекты каралганчы, 7 көннән дә соңга калмыйча уздырылалар. Гавами тыңлаулар белгечләр, экспертлар, кызыксынган затларны чакырып уздырыла. Гавами тыңлауларда теләге булган Җирлектә яшәүче һәрбер кеше катнашырга хокуклы.

8. Гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре буенча, компетенцияләрендә гавами тыңлауларга кертелүче муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү кергән җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең вазыйфаи затлары мәҗбүри рәвештә карарга тиешле рекомендацияләр кабул ителә.

9. Кабул ителгән карарның дәлилләнгән нигезләрен дә үз эченә алган гавами тыңлауларның нәтиҗәләре гавами тыңлаулар уздырылган көннән 5 көннән дә соңга калмыйча, әгәр законнарда башкасы каралмаса, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл бистәсе, Советская ур., 13 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Җирлек Советы тарафыннан раслана торган норматив хокукый акт белән билгеләнә.

11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне караган проектлар, җир кишәрлекләренең шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә яки капиталь төзелеш объектына рөхсәт бирү карарлары проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары чикләреннән тайпылышка рөхсәт бирү карары, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү, җирдән файдалануның һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен шундый файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре һәм төзү проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар уздырыла, аларны оештыру һәм уздыру тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, Җирлек Советының әлеге Уставы һәм (яисә) норматив хокукый акты белән билгеләнә.

**22 статья. Гражданнар җыелышы**

1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча фикер алышу, җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затларының эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү өчен Җирлек территориясенең бер өлешендә гражданнар җыелышлары уздырылырга мөмкин. Гражданнар җыены микрорайоннар, торак массивлар, квартал, урам, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыены халык, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы инициативасы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән каралган очракларда уздырыла.

3. Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы инициативасы белән уздырылучы гражданнар җыелышы, Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы белән уздырылучы гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, билгеле бер территориядә яшәүче

һәм җыелышларда катнашу хокукы булган халыкның 10 процентыннан да ким булмаган гражданнар төркеменең, әлеге территорияләрдә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренең язма мөрәҗәгате буенча, Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыелышы уздыру буенча тәкъдимдә каралырга кирә торган мәсьәләләр исемлеге, тәкъдим ителгән вакыт һәм җыен уздыру урыны булырга тиеш. Тәкъдим вәкиллекле затлар тарафыннан, әгәр дә җыелыш уздыру инициативасы белән гражданнар төркеме чыкса, әлеге гражданнарның һәрберсенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, туган көнен, яшәү урынын адресын күрсәтеп имзаланган булырга тиеш.

Җирлек Советы гражданнар җыелышы уздыру турында кертелгән тәкъдимне үзенең алдагы утырышында карый.

Җирлек Советы гражданнар җыелышы уздыруны аның максатка ярашлы булмавы дәлиле белән кире кагарга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру максатларында гражданнар җыелышы уздыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышы уздыру вакыты һәм урыны һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр буенча, билгеле территориядә яшәүчеләргә җыелыш уздырырга 7 көннән дә ким булмаган вакыт аралыгында массакүләм мәгълүмат чаралары, почта хәбәре, фатирларны (йортларны) йөреп чыгу, белдерүләр һәм башка мөмкин булган чаралар ярдәмендә хәбәр бирәләр.

Гражданнар җыены уздыруны әзерләүне һәм уздыруны Җирлек Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышларның эшендә әлеге территориядә яшәүче сайлау хокукына ия булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышларда катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны муниципаль сайлаулар уздырганда кулланыла торган Россия Федерациясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданнарын вакытлыча яшәү һәм яшәү урыны буенча теркәү хисабы мәгълүматлары буенча билгеләнә.

Җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнарның өчтән бер өлеше катнашса, гражданнар җыелышы тулы хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашучы гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм Җирлекнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затларына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итүче вәкиллекле затларны сайларга мөмкин.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру мәсьәләләре белән бәйле үткәрелә торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыенлышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр компетенцияләренә мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне хәл итү һәм язмача җавап җибәрү кертелгән җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары каравы мәҗбүри.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе, шулай ук гражданнар җыенының вәкаләтләре федераль законнар, әлеге Устав һәм Җирлек Советы норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы нәтиҗәләре бер ай эчендә рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**23 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)**

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча фикер алышу зарурлыгы килеп чыкканда һәм Җирлекнең бар халкы вәкилләренең фикерен белү өчен оештырыла. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек территориясенең бер өлешендә яшәүче халык арасыннан, гражданнар җыелышы җыю кыен булган очракларда, шулай ук тиешле территориядә яшәүче гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган халык саны 100 кешедән артканда оештырыла.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышы) билгеләү һәм уздыру, делегатлар сайлау тәртибе әлеге Устав, Җирлек Советы норматив хокукый актлары, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен тормышка ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы инициативасы белән уздырыла. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы инициативасы белән уздырылучы гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), Җирлек Советы һәм Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы белән уздырылучы гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) тулы хокуклы дип анда тиешле территориядә уналты яше тулган яшәүчеләрнең өчтән бер өлешен тәкъдим итүче гражданнар җыелышларында сайланган граждан-делегатларның өчтән ике өлеше катнашса санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) нәтиҗәләре ул уздырылганнан соң бер ай эчендә рәсми рәвештә бастырып чагырылырга (халыкка җиткерелергә) тиешле.

**24 статья. Гражданнар җыены**

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында күрсәтелгән очракларда гражданнар җыены уздырылырга мөмкин:

- торак пунктта составына күрсәтелгән торак пункт керүче Җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка Җирлек территориясенә (муниципаль район) керү мөмкинлеге булган очракта;

- Җирлек составына керүче торак пунктта, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарга үзара салым акчасы чаралары кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча;

- авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләрен алдан туктату мәсьәләсе буенча.

2. Авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын башкару өчен конкурс уздырган вакытта конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатыннан уздырылырга мөмкин.

3. Әлеге статья белән каралган гражданнар җыены аңарда торак пунктта яки Җирлектә сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан күбрәге катнашса тулы хокуклы була. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булганнарның яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, әлеге устав нигезендә гражданнар җыены, гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган чорда этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар. Әлеге гражданнар җыены карары гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан күбрәге аның өчен тавыш бирсә кабул ителгән булып санала.

4. Гражданнар җыены уздыру тәртибе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә раслана.

**25 статья. Гражданнарны сораштыру**

1. Гражданнарны сораштыру Җирлекнең барлык территориясендә яки территориянең аерым бер өлешендә җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә халык фикерен исәпкә алу максатыннан уздырыла.

Сораштыру нәтиҗәләре рекомендация характерын йөртә.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия булган Җирлек халкы катнашырга хокуклы.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәгеләр инициативасы белән уздырыла:

1) Совет яки Җирлек Башлыгы – җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары – республика һәм республикара әһәмияткә ия объектлар өчен Җирлек җирләрен максатчан билгеләүне үзгәртү турындагы карарларны кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе Җирлек Советы норматив хокукый актлары белән Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карар Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Җирлек Советының гражданнарны сораштыру билгеләү турында карарында билгеләнәләр:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителәчәк сорауның (сорауларның) формулировкасы;

3) сораштыру уздыру методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы Җирлек халкының минималь саны.

6. Җирлек халкына гражданнарны сораштыру уздырылуы турында аны уздыруга кадәр 10 көн алдан хәбәр итәләр.

7. Гражданнарны сораштыру белән чараларны әзерләү һәм уздыруны финанслау башкарыла:

1) Җирлек бюджеты чаралары хисабына – гражданнарны сораштыру Җирлек җирле үзидарә органнары инициативасы белән уздырылганда;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына – гражданнарны сораштыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән уздырылганда.

8. Сораштыру нәтиҗәләре уздырылганнан соң бер ай дәвамында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиешле. Сораштыру нәтиҗәләре белән Җирлекнең һәр кешесе танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре Җирлек җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

## 26 статья. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы

1. Муниципаль хокук актлары проектларын һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләрне халык фикер алышуына чыгару турында карар Җирлек Советы тарафыннан үз инициативасы буенча яки шушы территориядә яшәгән гражданнар таләбе буенча Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

2. Муниципаль хокук актлары проекты тексты һәм башка халык фикер алышуына чыгарылган мәсьәләләр буенча башка материалларны халык фикер алышуына чыгару турында карар кабул ителгән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырыла, Җирлек халкына таратыла, халык таныша алырлык урыннарда урнаштырыла, башка юллар белән халыкка җиткерелә.

3. Халык фикер алышуына мәсьәләләрне чыгару белән беррәттән, Җирлек Советы фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне карау буенча эшне оештыру вакытын һәм тәртибен билгели, күрсәтелгән максатлар өчен махсус комиссия төзи.

4. Җирлек Советы аның тарафыннан кертелгән муниципаль хокук актлары проектларын һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләре буенча фикер алышуны тәэмин итә, моның өчен шартлар тудыра.

5. Халык фикер алышуына чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр Җирлек Советына җибәрелә.

6. Муниципаль хокук актлары проектлары һәм башка аеруча әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр Җирлек Советы тарафыннан карала.

7. Халык тикшерүе нәтиҗәләре турында халыкка бер ай эчендә хәбәр ителә.

## 27 статья. Җирлекнең иҗтимагый (консультатив) советлары

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм гражданнарының үзара хезмәттәшлеген булдыру өчен, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча карарлар эшләгәндә һәм тормышка ашырганда халык мәнфәгатьләрен һәм

ихтыяҗларын исәпкә алу максатыннан, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген иҗтимагый контрольдә тоту өчен Җирлекнең иҗтимагый советы төзелә.

2. Җирлекнең иҗтимагый советы аның эшчәнлегендә Җирлек халкының, иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның ирекле катнашуы нигезендә барлыкка килә.

3. Җирлекнең иҗтимагый советын оештыру тәртибе, вәкаләтләре, аның утырышларын үткәрү һәм карарлар кабул итү тәртибе, Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Җирлекнең иҗтимагый советы эшчәнлегенә мәгълүмати, консультатив ярдәм итү хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, аны тарату процедурасы, шулай ук аның оештырылуы һәм эшчәнлеге буенча башка мәсьәләләр Җирлек Советы раслаган нигезләмә белән билгеләнә.

4. Башка иҗтимагый (консультатив) советлар Җирлекнең җирле үзидарә органнары каршында, аларның карарлары нигезендә барлыкка килергә мөмкин.

5. Иҗтимагый (консультатив) советларда эш җәмәгатьчелек тәртибендә башкарыла.

**28 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләре**

1. Гражданнар Җирлекнең җирле үзидарә органнарына шәхси һәм коллектив мөрәҗәгатьләр белән чыгарга хокуклы.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарә вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тоталар.

**29 статья. Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыруның һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашуы башка формалары**

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру формалары һәм халыкның җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашу формалары белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне тормышка ашыруның башка төр Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән формаларында катнашырга хокуклы.

2. Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыруы һәм халыкның җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуы законлылык, иреклелек принципларына нигезләнә.

Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыруына һәм халыкка җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуында ярдәм күрсәтергә тиеш.

## III Бүлек. ҖИРЛЕК СОВЕТЫ

### 30 статья. Җирлек Советы – Җирлекнең җирле үзидарәсе вәкиллекле органы

1. Җирлек Советы - җирле үзидарәнең даими гамәлдәге коллегиаль вәкиллекле сайлап куелган органы булып тора.

2. Җирлек Советының рәсми исеме – “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы”

3. Җирлек Советының вәкаләтлек вакыты – биш ел.

4. Җирлек Советы Җирлектә яшәүчеләр алдында хисап тота һәм алар контрольлегендә.

5. Җирлек Советының мөһере һәм үзенең атамалары белән бланклары бар.

6. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыруга чыгымнар Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнар классификациясенә туры китереп Җирлек бюджетында аерым юл белән карала.

### 31 статья. Җирлек Советы составы

1. Җирлек Советы муниципаль сайлауларда бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлап куелган **10** депутаттан тора.

2. Җирлек Советы аның составына Җирлек Советы билгеләгән саннан өчтән икесеннән ким булмаган өлеш депутатларны сайлаганда хокуклы була.

### 32 статья. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарә органының сайлаулы органы әгъзасы, Җирлек Башлыгы статусы

1. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарә органының сайлаулы органы әгъзасы, Җирлек Башлыгы вәкаләтләре аны сайлап куйган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Җирлек Советы эшен башлаган көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарә органының сайлаулы органы әгъзасы, Җирлек Башлыгы әлеге Устав белән билгеләнгән очраклардан кала, азат ителмәгән эшкә таянып депутат эшчәнлеген төп эш урынындагы хезмәт вазифалары белән берләштереп алып бара.

3. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарә органының сайлаулы органы әгъзасы, Җирлек Башлыгы статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

4. Җирлек Советы депутатына, үзенең вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары нигезендә шартлар тәэмин ителә.

5. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары бинада, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук аларны үткәрү тормышны тәэмин итү объектларының, транспорт һәм социаль инфраструктура, элемтә эшчәнлеген бозуга китермәгән, җәяүлеләр һәм транспорт йөрешенә, яки гражданнарның торак йортларга, транспорт һәм иҗтимагый инфраструктура объектларына керү юлларында комачаулык тудырмаган шартларда, ишегаллары эчендәге территорияләрдә үткәрелә. Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына яки җирле үзидарә органнарына белдерү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат

күрсәтелгән органнарга алдан ук аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итәргә хокуклы.

6. Җирлек Башкарма комитеты депутатларның сайлаучылар белән очрашу үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашу өчен бирелгән биналарның исемлеген һәм аларның бирелү тәртибен билгели.

7. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары халык алдындагы чара формасында Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

8. Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы Россия Федерациясе законнары билгеләгәнчә, депутатның халык алдындагы чара формасында оештырылган һәм үткәрелгән сайлаучылар белән очрашуларына каршылык итү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылык каралган.

9. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Җирлек башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм (кертемнәр) кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) финанс инструментларына ия булуны тыю турында тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, әгәр башкасы әлеге 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон белән каралган булмаса, чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракларда Җирлек Советы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, Җирлек Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

10. Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында законы нигезендә Җирлек Советы депутатының, Җирлек Башлыгының, җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълуматларының дөреслеге һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы законы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) карары буенча үткәрелә.

11. Әлеге статьяның 10 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012

елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны сакламау һәм вазифаларын үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты Җирлек Советы депутатының, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасының, Җирлек Башлыгының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында яки күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чарасы куллану турында җирле үзидарәнең тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле органына яки судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

12. Үз керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән Җирлек Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Җирлек Башлыгына, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр бу белешмәләрне бозу зур дәрәҗәдә булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итеп, вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) вәкаләтләр чоры туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләр чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

13. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге статьяның 12 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

14. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге веб-адрес буенча рәсми сайтында урнаштырыла: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирелә.

**33 статья. Җирлек Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар белән, шулай ук аның сайлау территориясендә урнашкан предприятие, оешма, дәүләт һәм башка органнар коллективлары белән элемтәдә тора.

2. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм хисап тота.

3. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында елга кимендә бер мәртәбә үз эшчәнлеге турында хисап тота, вакыт-вакыт Җирлек Советы эше хакында мәгълүмат бирә, шулай ук айга кимендә бер мәртәбә халыкны кабул итүләрүткәрә.

4. Җирлек Советы депутаты законлы хокуклар, ирек һәм район халкы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнар тарафыннан билгеләнгән чаралар күрергә, шулай ук алардан килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга һәм анда күрсәтелгән мәсьәләләрне вакытында дөрес итеп чишәргә булышырга тиеш.

**34 статья. Яңа сайланган Җирлек Советының эшен оештыру**

1. Яңа чакырылыш Җирлек Советы беренче утырышка Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынан кимендә өчтән ике өлеше сайланган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң беренче Җирлек Советы утырышы Җирлек Башлыгы тарафыннан чакырыла, ул булмаган очракта – Җирлекнең Сайлау комиссиясе тарафыннан.

2. Җирлек Советының сайлаулардан соң беренче утырышын яңа Җирлек Башлыгы сайланганчы Җирлек Советының яшь буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара.

**35 статья. Җирлек Советы компетенциясе**

1. Җирлек Советы компетенциясенә керәләр:

1) Уставны кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәлмәләр кертү;

2) законнар нигезендә Җирлек территориясендә гомуми мәҗбүри кагыйдәләр урнаштыру;

3) Җирлек бюджетын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

4) Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару аларны түләү буенча льготалар билгеләү;

5) Җирлекнең социаль-икътисади стратегиясен раслау;

5.1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисади үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән, Җирлекнең муниципаль идарәсе һәм социаль-икътисади үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

5.2) җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлыштыру документларын эшләп чыгару, карау, раслау (хуплау);

5.3) җирле үзидарә органнары белән расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруның мониторингы һәм контроле;

5.4) федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән стратегик планлаштыру өлкәсендә башка вәкаләтләр;

6) Җирлек чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору буенча инициатива чыгару;

7) Җирлек Советына депутатлар сайлауны билгеләү һәм Җирлек Советы депутатларын сайлау буенча сайлау округлары схемаларын раслау;

8) җирле референдумны билгеләү;

9) Җирлек Башлыгын билгеләү;

10) Җирлек Башлыгы урынбасарын билгеләү;

11) Биектау муниципаль районы Советына Җирлек Советы депутаталары арасыннан Җирлек вәкилен сайлау;

12) Җирлекнең Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләре санының иң чик күләмен урнаштыру;

13) Җирлекнең Сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

14) Җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, Җирлек Башлыгын кире чакыру буенча тавыш бирүне билгеләү;

15) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру;

16) Җирлекнең муниципаль милкендәге милек белән идарә итү һәм гамәл кылу тәртибе;

17) муниципаль предприятие һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртү һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү, шулай ук федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль предприятиеләренең һәм учреждениеләрнең хезмәтенә күрсәтүенә, эш башкаруына тарифларны билгеләү;

18) Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлекне оештыруда катнашу тәртибен билгеләү;

19) Җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру һәм материаль - техник тәэмин итү тәртибен билгеләү;

20) Җирлекнең Ревизия комиссиясен формалаштыру;

21) Җирлек Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

22) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

23) Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне башкаруын контрольдә тоту;

24) Җирлек бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарәгә кирәкле чаралар бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

25) коммерцияле булмаган автоном оешмалар һәм фондлар формасында коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

26) үзенең басма массакүләм мәгълумат чараларын оештыру;

27) Җирлек Уставын һәм Җирлек Советы карарларын аңлату;

28) үзенең эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Җирлек Советы Регламентын һәм башка карарларны кабул итү;

29) Җирлек гражданнарының закон чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибен, территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру һәм Җирлек бюджетыннан кирәкле чараларны бүлеп бирү тәртибен, гражданнар конференцияләрен (делегатлар җыелышы), гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибен билгеләү;

30) Советның депутат комиссияләре составын оештыру, раслау һәм үзгәртү;

31) Җирлекнең территориаль планлаштыру документларын, Җирлекнең шәһәр төзелеше проектлары җирле нормативларын, Җирлек территориясе җирләреннән

куллану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен, башка шәһәр төзелеше документларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә раслау;

32) депутат соратуларын карау һәм алар буенча карарлар кабул итү;

33) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру;

34) Җирлек Советы депутатларын һәм Җирлек Башлыгын сайлаулар билгеләү турында карар кабул итү;

35) Җирлекнең муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен урнаштыру;

36) муниципаль янгыннан саклану оештыру турында карар кабул итү, Җирлек территориясендә муниципаль янгыннан саклану эшчәнлегенең максатларын, бурычларын һәм оештыру тәртибен, аның башка төр янгыннан саклану оешмалары белән хезмәттәшлек тәртибен билгеләү;

37) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы беренчел чараларын оештыру-хокукый, финанс һәм материаль-техник тәэмин итү тәртибе турында карар кабул итү;

38) Җирлек территориясендә оборона өлкәсендә, үз компетенциясе чикләрендә, хәрби идарә органнары белән хезмәттәшлек итеп законнар үтәлүне тәэмин итү;

39) муниципаль район Советына Җирлек Советы депутатлары арасыннан Җирлек вәкилен сайлау;

40) Совет, авыл Җирлеге Башкарма комитеты һәм күрсәтелгән органнар эшчәнлеге белән бәйле яки аларның карамагында булган оешмаларның мобилизациясен һәм мобилизацион әзерлеге белән җитәкчелек итү, тәэмин итү һәм оештыру;

41) җирле үзидарә органнарының сайлап куелган вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, Җирлек Советы депутаталарына, муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждение хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, мәгариф турында Россия Федерациясе законнары һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру;

42) Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары тарафыннан Җирлекнең вәкиллекле органнары карамагындагы вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән Җирлек Советы компетенциясенә кагылышлы башка төр вәкаләтләр.

2. Җирлек Советы ел саен Җирлек Башлыгының үзенең эшчәнлеге, Җирлекнең Башкарма комитеты эшчәнлеге, башка Җирлек Башлыгы карамагында булган җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне дә хәл итү турында хисапларын тыңлый.

### 36 статья. Җирлек Советының эш тәртибе

1. Җирлек Советы эш тәртибе әлеге Устав һәм Җирлек Советы Регламенты белән билгеләнә.

2. Җирлек Советы эшчәнлегенең төп формасы булып Җирлек Советы компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итүче утырышлар тора.

3. Җирлек Советы утырышы сайланган депутатлар санынннан 50 процентыннан ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

4. Җирлек Советының чираттагы утырышлары зарурлык туган саен, тик өч айга бер тапкырдан да ким булмаганча үткәрелә. Чираттан тыш утырышлар Җирлек Башлыгы яки Җирлек Советы депутатлар төркеменең билгеләнгән санынннан өчтән бер өлеше инициативасы белән чакырыла.

5. Совет утырышлары Җирлек Башлыгы тарафыннан чакырыла. Җирлек Советы депутатлары һәм чакырылган затлар чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм чираттагы утырышның көн тәртибендәге мәсьәләләре турында кимендә биш көн алдан, ә чираттан тыш киңәшмәгә – кимендә бер көн алдан хәбәр ителәләр.

6. Җирлек Советы утырышлары ачык һәм белдереп үткәрелә. Җирлек Советының ачык утырышларында Җирлекнең теләсә кайсы кешесе катнаша ала.

Регламент белән каралган очракларда, Җирлек Советы ябык утырышлар үткәрү турында карар кабул итергә хаклы, һәм анда Җирлек Советы чакырган затлар гына, шулай ук законнар нигезендә утырышта катнашырга хокукы булган затлар катнаша ала.

7. Җирлек Советының һәрбер утырышында беркетмә алып барыла. Беркетмәгә дата, утырышны уздыру урыны һәм вакыты турында мәгълүматлар кертелә, каралучы барлык мәсьәләләр санала һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен күрсәтеп кабул ителгән бар карарлар теркәлә. Җирлек Башлыгы Җирлек Советы киңәшмәсенең беркетмәсен имзалаганнан соң, аның белән Җирлекнең һәрбер кешесе таныша ала.

8. Җирлек Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Җирлек Советы депутаты үзенең тавыш бирергә хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Җирлек Советы утырышында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп тә) һәм ябык була ала. Һәр тавыш бирү төрен куллану очраклары әлеге Устав, Җирлек Советы Регламенты белән билгеләнә.

### 37 статья. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру

1. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыруны Җирлек Башлыгы гамәлгә ашыра.

2. Җирлек Советы Регламенты нигезендә, Җирлек Советы компетенциясенә караган мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан, Җирлек Башлыгы һәм аның урынбасарыннан кала, Җирлек Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими яки вакытлы комиссияләр оештырыла ала (яки) Җирлек Советы эшчәнлегенең төп эш юнәлешләре буенча күрсәтелгән мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы булган депутатлар билгеләнә. Депутат икедән артык булмаган даими комиссиядә эшләргә хокуклы.

3. Җирлек карамагына кертелгән муниципаль программалар, Җирлек Советы карарлары проекты, аеруча әһәмиятле мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен Җирлек Советы каршында аларны чишү буенча депутатлар, Җирлек Башкарма комитеты вәкилләре, иҗтимагый берләшмәләр, оешма һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм Җирлек халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре оештырылырга мөмкин.

### 38 статья. Җирлек Советы тарафыннан контроль функцияләрен башкару

1. Җирлек Советы район территориясендә әлеге Устав нигезләмәләрен, Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган норматив актларның, Җирлек

бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш фонд чарарлары кулланылышын, Җирлек үсеше программалары үтәлешен, Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм аларны вазыйфаи затлары тарафыннан законнарны, әлеге Уставны һәм башка норматив хокуый актларны кагыйдә бозу фактлары ачыкланса Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы карары нигезендә, депутатлар арасыннан ачыкланган фактларны тикшерү өчен вакытлы контроль комиссияләре оештырылырга мөмкин.

3. Законнар нигезендә, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы инициативасы белән, Җирлек бюджеты чараларын максатчан куллану, муниципаль милекне эффектив куллану буенча тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелергә мөмкин. Күрсәтелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларны уздыру тәртибе Җирлекнең ревизия комиссиясе турындагы Нигезләмә тарафыннан билгеләнә

4. Җирлек Башкарма комитеты, предприятие, учреждение, оешмалар, вазыйфаи затлар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, закон белән башкасы билгеләнмәсә, Җирлек Советы, аның контроль комиссиясе, Җирлек Советы депутаты мөрәҗәгате буенча Җирлек Советы карамагында булган мәсьәләләр буенча соратылган мәгълүматны тапшырырга тиешле, законнарны, муниципаль норматив хокукый актлар бозылган очракта кичекмәстән бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә тиеш.

5. Җирлек Советы Җирлек Башлыгының аның эшчәнлеге, Җирлек Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең ведомство карамагындагы башка органнарының эшчәнлеге, шул исәптән Җирлек Советы белән куелган мәсьәләләрне хәл итү нәтиҗәләре буенча еллык хисабын тыңлый.

6. Җирлек Советы контроль функциясен тормышка ашырганда, Җирлек Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкару-җитәкчелек итү эшчәнлегенә катнашырга тиеш түгел.

### 39 статья. Биектау муниципаль районы Советына Җирлек вәкиле сайлау

1. Җирлек вәкиле Биектау муниципаль районы Советына яшерен тавыш бирү юлы белән Җирлек Советы депутатлары арасыннан сайлана.

2. Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан күбрәге аның өчен тавыш биргән кандидат сайланган дип санала.

### 40 статья. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Җирлек Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) Совет тарафыннан үзтаратылу буенча карар кабул итү. Шул ук вакытта үзтаратылу турында карар әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә кабул ителә;

2) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 нче статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм нигезләр буенча тарату;

3) Татарстан Республикасы Югары суды Җирлек Советы депутатларының әлеге составы хокуклы түгеллеге турында карар үз көченә керсә, шул исәптән депутатлар үз вәкаләтләрен төшерүләре белән бәйле рәвештә;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары

турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла торган Җирлекне үзгәртеп төзү, шулай ук Җирлекне бетерү очрагында;

5) шәһәр округы белән кушылу нәтиҗәсендә Җирлекнең муниципаль берәмлек статусын югалтуы;

6) Җирлек чикләрен үзгәртү яки Җирлекнең шәһәр округы белән кушылуы нәтиҗәсендә Җирлектә сайлаучылар саны 25 проценттан да күбрәккә артып китүе;

7) гражданнарның турыдан-туры теләк белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны бастыру сроклары бозылганда.

2. Җирлек Советы вәкаләтләренең вакыттыннан алда туктатылуы аның депутатлары вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуына китерә.

3. Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, вакытыннан алда сайлаулар "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән срокларда уздырыла.

**41 статья. Җирлек Советын үзтарату буенча карар кабул итү тәртибе**

1. Җирлек Советын үзтарату буенча карар Җирлек Башлыгы яки Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган депутатлар төркеме инициативасы белән кабул ителергә мөмкин.

2. Үзтарату буенча карар чыгару инициативасы чыгарыла алмый:

1) Җирлек Советы сайланганнан соң бер ел эчендә;

2) Җирлек бюжетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисап расланган вакытта;

3) Җирлек Башлыгын кире чакыртып алу турында тавыш бирү вакытында яисә аның вәкаләтләре алдан туктатылган очракта.

3. Җирлек Советын үзтарату турында язма тәкъдим үзтарату мотивларын үз эченә алырга тиеш, шулай ук аңа үзтарату сәбәпләре нигезләнгән башка төр материаллар да беркетелергә мөмкин.

4. Үзтарату турында мәсьәләне алдан карау өчен Җирлек Советы карары белән депутатлар арасыннан комиссия төзелә. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы карары нигезендә Җирлек Советын үзтарату мәсьәләсе гавами тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Җирлек Советын үзтарату мәсьәләсен карау дәвамлылыгы Җирлек Советы депутатлары һәм Җирлек халкы тарафыннан үзтарату инициативасының барлык хәлләре һәм дәлилләрен һәрьяклап һәм объектив карау мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үзтарату турында карар үзтарату турында инициатива чыгарылган көннән соң ике ай узып кабул ителергә мөмкин

6. Җирлек Советын үзтарату турында карар яшерен тавыш бирү юлы белән Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

7. Җирлек Советы тарафыннан үзтарату тәкъдимен кире каккан очракта, үзтарату турында кабат инициатива үзтарату мәсьәләсе буенча тавыш бирү көненнән кимендә бер елдан соң чыгарылырга мөмкин.

**42 статья. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;

3) суд тарафыннан хезмәткә яраксыз яки эшкә чикле яраклы дип табылса;

4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керсә;

6) Россия Федерациясе чикләреннән читкә даими яшәргә китсә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, әлеге килешү нигезендә чит ил гражданины җирле үзидарә органнарына сайланырга, Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе белән халыкара килешүдә катнашмаган чит ил территориясендә яшәргә хокуклы икәнен дәлилләүче, чит ил гражданины гражданлыгы алырга, тору өчен рөхсәт яки башка төр документ алырга хокуклы, шуның белән бәйле рәвештә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданины җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия;

8) сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алынса;

9) Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса;

10) хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә алынса;

11) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

12) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәмәү;

13) федераль законнар белән билгеләнгән башка очракларда.

2. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен туктату турындагы карар әлеге статьяның 1 өлешенең 1-8, 10-12 пунктларында күрсәтелгән очракларда вакытыннан алда вәкаләтләрне туктату өчен нигез барлыкка килгәннән 30 көннән дә соңга калмыйча Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә, әгәр бу очрак Җирлек Советы утырышлары арасында булса, мондый нигез барлыкка килгән көннән өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

3. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында каралган очракта Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән туктатыла.

4. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, депутатны өстәмә сайлаулар федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктатуга нигез булып Җирлек Советына әлеге гариза кергән көн санала.

## IV Бүлек. ҖИРЛЕК БАШЛЫГЫ

### 43 статья. Җирлек Башлыгы – Җирлекнең югары вазыйфаи заты

1. Җирлек Башлыгы Җирлекнең югары вазыйфаи заты булып санала

2. Җирлек Башлыгы Җирлек Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе булып тора.

3. Җирлек Башлыгы вазыйфасының рәсми исеме – "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башлыгы".

4. Җирлек Башлыгы вазыйфасы буенча Биектау муниципаль районы Советы депутаты булып тора.

5. Җирлек Башлыгы турыдан-туры Җирлек халкы һәм Советы контроле астында һәм алар алдында хисап тота.

### 44 статья. Җирлек Башлыгын сайлау тәртибе

1. Җирлек Башлыгы яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында Җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән, әгәр Җирлек Советы башка тавыш бирү тәртибе билгеләмәсә, Җирлек Советы вәкаләте вакытына сайлана.

Җирлек Башлыгын сайлау Җирлек Советы депутатлары күрсәткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән Җирлек халкы, иҗтимагый оешмалар, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек Советы депутаты Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан күбрәге аны сайлау өчен тавыш бирсә, Җирлек Башлыгы итеп сайланган санала.

3. Сайланганнан соң Җирлек Башлыгы түбәндәгечә ант бирә:

**«Миңа йөкләнгән Җирлек Башлыгының олы бурычларын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Конституциясен һәм законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, Җирлек Уставын үтәргә, Җирлек кешеләренең мул тормышын тәэмин итү өчен бөтен көчемне һәм белемемне куярга, кеше һәм гражданин ирекләрен һәм хокукларын якларга ант итәм».**

### 45 статья. Җирлек Башлыгы статусы

1. Җирлек Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Җирлек Башлыгын Биектау муниципаль районы Советына даими нигездә биләүче вазыйфага сайланган очракта, ул җирлек Башлыгы вазыйфаларын даими булмаган нигездә тормышка ашыра.

3. Җирлек Башлыгы үзенең эшчәнлегендә әлеге Устав һәм федераль закон нигезендә Җирлек Советына һәм Җирлектә яшәүчеләрнең контрольлегендә һәм алар алдында хисап тота.

4. Җирлек Башлыгы кимендә елга бер тапкыр Җирлек Советы алдында үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре, Җирлек Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең аңа ведомство карамагындагы башка органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Җирлек Советы куйган мәсьәләләрне чишү турында хисап тота.

5. Җирлек Башлыгы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәргә тиеш.

**46 статья. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре**

1. Җирлек Башлыгы үзенең вәкаләтләре кысаларында:

1) Җирлекне башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә, Җирлек исеменнән ышанычнамәсез эш итә;

2) Җирлек Советы эшен оештыра, Җирлек Советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә;

3) әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә Җирлек Советы кабул иткән норматив хокукый актларны имзалый һәм халыкка җиткерә;

4) үз вәкаләтләре чикләрендә Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

5) Җирлек Советына үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча ел саен хисап тапшыра;

6) Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

7) Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән билгеләнгән тәртиптә яңа җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе билгеләнгәнчегә кадәр чорда җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары вазыйфасына билгеләп куя һәм азат итә.

8) Җирлек Советы эшендә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны һәм ачыклыкны тәэмин итү буенча чаралар күрә;

9) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

10) Җирлек Советы утырышлары беркетмәләрен имзалый;

11) Җирлек Советы аппараты эше белән җитәкчелек итүне оештыра;

12) Җирлек Советының контрольлек итү вәкаләтләрен координацияли;

13) Җирлек Советын эшчәнлеген карап тоту һәм тәэмин итүгә җирлек бюджетында каралган чыгымнар буенча чараларны бүлүче булып тора;

14) законнар һәм әлеге Устав нигезендә, гражданнарның турыдан-туры теләк белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча Җирлек Советы хокукый актын кабул итүне оештыра;

15) Җирлек җирле үзидарәсе органнарының җирлек территориясендә гамәл кылучы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән кирәкле үзара бәйләнешне тәэмин итә;

16) Җирлек исеменнән дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән икътисади һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек һәм эшчәнлекне координацияләү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

17) бюджетның агымдагы үтәлешен контрольдә тота;

18) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлек башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Устав, җирлек Советы карарлары белән җирлек Башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Җирлек башлыгы вакытлыча булмаган яки үзенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, әлеге мәсьәлә буенча махсус чыгарылган хокукый акт нигезендә, Җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи заты аның вәкаләтләрен тулы күләмдә башкара.

3. Җирлек Башлыгы Җирлек Советына үзенең эшчәнлеге, башкарма комитет эшчәнлеге турында, шул исәптән Җирлек Советы куйган мәсьәләләрне чишү турында еллык хисапларын тапшыра.

**47 статья.** Җирлек Башлыгы урынбасары

1. Җирлек Башлыгы урынбасары Җирлек Башлыгы тәкъдиме белән Җирлек Советы депутатлары арасыннан сайлана.

2. Җирлек Башлыгы урынбасары, Җирлек Советы тарафыннан башка тавыш бирү тәртибе билгеләнмәгән булса, яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

3. Җирлек Советы депутаты аны сайлау өчен Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, Җирлек Башлыгы урынбасары итеп сайланган булып санала.

4. Җирлек Башлыгы урынбасары Җирлек Советы Регламенты билгеләгән йөкләмәләрне бүлү нигезендә функцияләр башкара, Җирлек Башлыгы йөкләмәләрен үти.

Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яисә аңа карата сак астына алу рәвешендә суд карары белән процессуаль мәҗбүри чаралар кулланылганда яки ул вакытлыча булмаса (авыру яки түләүле ялга китү сәбәпле), яки аның тарафыннан үз вазыйфаларын үтәү мөмкин булмаганда, аның вәкаләтләрен вакытлыча Җирлек Башлыгы урынбасары башкара.

5. Җирлек Башлыгы урынбасары үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыра.

6. Җирлек Башлыгы урынбасары вәкаләтләре әлеге Уставның 41 статьясында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла.

7. Җирлек башлыгы урынбасары теләсә кайсы вакытта Җирлек башлыгы инициативасы белән кабул ителә торган Җирлек Советы карары буенча яки Җирлек Советында депутатларның билгеләнгән санынннан өчтән береннән дә ким булмаган санда депутаталар төркеме таләбе белән вазыйфасыннан алынырга мөмкин. Җирлек башлыгы урынбасарын чакыртып алу карары Җирлек Советында депутатларның билгеләнгән санынннан күпчелеге тавыш бирүе белән кабул ителә.

8. Җирлек башлыгы урынбасары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 03.12.2012 № 230-ФЗ Федераль законы, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәргә тиеш.

9. Җирлек Башлыгы урынбасарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав белән, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

## 48 статья. Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу очраклары:

1) үлеме;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага җибәрү;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан баш тарту;

5) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә өлешчә сәләтсез дип танылуы;

6) суд тарафыннан хәбәрсез юк булуы яки үлгән дип хәбәр ителүе;

7) судның аңа карата булган гаепләү хөкем карарының законлы көченә керүе;

8) даими яшәү өчен Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, әлеге килешү нигезендә чит ил гражданины җирле үзидарә органнарына сайланырга, Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе белән халыкара килешүдә катнашмаган чит ил территориясендә яшәргә хокуклы икәнен дәлилләүче, чит ил гражданины гражданлыгы алырга, тору өчен рөхсәт яки башка төр документ алырга хокуклы, шуның белән бәйле рәвештә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданины җирле үзидарә органнарына сайлана алу хокукына ия;

10) сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алу;

11) сәламәтлеге буенча Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен башкарырга ныклы сәләтсез дип суд тәртибендә билгеләнсә;

12) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырылган Җирлекне үзгәртеп кору, шулай ук Җирлекнең бетерелүе очрагында;

13) шәһәр округы белән кушылуы нәтиҗәсендә Җирлекнең муниципаль берәмлек статусын югалтуы;

14) Җирлек чикләре үзгәрү яки Җирлекне шәһәр округы белән кушу нәтиҗәсендә Җирлектә сайлаучылар саны 25 проценттан да күбрәккә артып китүе;

15) нарушения срока издания муниципального правового акта, требуемого для реализации решения, принятого путем прямого волеизъявления граждан;

16) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

17) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 03.12.2012 № 230-ФЗ Федераль законы, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәмәве;

2. Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен әлеге статьяның 1 бүлеге 1-11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Җирлек Башлыгын сайлау мондый вәкаләтлек туктатылган көннән алты айдан соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта җирлек Советы вәкаләтләре вакыты чыгарга алты айдан ким вакыт калса, Җирлек Башлыгын сайлау яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында тормышка ашырыла.

3. Җирлек Советы аны отставкага чыгару турында карар кабул иткән Җирлек Башлыгы күрсәтелгән карарга шикаять бирү турындагы гариза белән мондый карар рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн эчендә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) вазыйфасыннан баш тарту турында аңа карата хокукый акт чыгарылган Җирлек Башлыгы рәсми басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә әлеге хокукый актка суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

4. Татарстан Республикасы Президентының (Татарстан Республикасы Премьер Министры) җирлек Башлыгын вазифадан баш тарту турында хокук акты нигезендә, яки җирлек Советының җирлек Башлыгын отставкага җибәрү турында карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган җирлек Башлыгы әлеге хокук актын яки карарны суд тәртибендә шикаять биргән очракта, суд карары законлы көченә кермичә Җирлек Советы үзенең составыннан сайлана торган Җирлек Башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хаклы түгел.

## V Бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**49 статья. Җирлек Башкарма комитеты - Җирлекнең җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы булып тора.

2. Җирлек Башкарма комитетының рәсми исеме – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты».

3. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек Советы контролендә һәм аның алдында хисап бирә.

4. Җирлек Башкарма комитеты мөһергә һәм үзенең атамалары һәм билгеләнгән үрнәктә Җирлек гербы сурәте белән бланкларына, шулай ук аңа тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт регистрациясе үткәрү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Россия Федерациясе гербы сурәте белән мөһергә ия.

5. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыруга чыгымнар Россия Федерациясе чыгымнар классификациясе нигезендә Җирлек бюджетында аерым юл белән карала.

**50 статья. Җирлек Башкарма комитеты структурасы**

1. . Башкарма комитет структурасы Җирлек Советы тарафыннан Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе тәкъдиме буенча раслана.

2. Җирлек Башкарма комитеты структурасына Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасары, Җирлек Башкарма комитетының башка вазыйфаи затлары һәм (яки) өлкә (функциональ) органнары керә.

**Статья 51. Полномочия исполнительного комитета Поселения**

Башкарма комитет түбәндәге бюджет вәкаләтләрен башкара:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәп өлкәсендә:

- Җирлекнең бюджет проектын эшләп чыгара;

- Җирлек бюджеты үтәлешен тәэмин итә; Җирлек үсешенең социаль-икътисади стратегиясен үтәүне оештыра;

- Җирлек бюджеты үтәлеше турында, Җирлек үсеше социаль-икътисади стратегиясе турында хисап әзерли;

- Җирлекнең социаль өлкәсе, икътисади хәлен характерлаучы статистик күрсәткечләрен җыюны оештыра һәм күрсәтелгән мәгълүматларны дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыра;

- "Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыра;

2) муниципаль милек белән идарә итү, Җирлек территориясендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- Җирлекнең муниципаль милкендә булган милек белән идарә итә, муниципаль милектә булган объектларны барлыкка китерү, алу, куллану һәм арендага бирү буенча мәсьәләләрне чишә;

- Җирлек Советы карары белән билгеләнә торган очракларда Җирлек Советына муниципаль милекне аерып алу, шул исәптән хосусыйлаштыру буенча тәкъдимнәр әзерли һәм килештерүгә (раслауга) кертә;

-муниципаль милектә булмаган предприятие, оешмалар белән Җирлекнең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында килешүләр төзи; Җирлек территориясендә төрле милек формасында халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче предприятиеләр оештыруга ярдәм итә;

-Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә муниципаль предприятие һәм учреждениеләр оештыра, алар эшчәнлегенең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрне финанслауны тәэмин итә, муниципаль предприятие һәм учреждениеләрне үзгәртеп кору һәм юк итү мәсьәләләрен хәл итә, аларның җитәкчеләрен контракт нигезендә билгели һәм биләгән вазыйфасыннан азат итә;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып ала; бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр башкаручы муниципаль йөкләмәләрне финанс яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- депутатларга сайлаучылар белән очрашу өчен махсус бирелгән урыннарны билгели, шулай ук депутатларга сайлаучылары белән очрашулар үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен ачыклый;

3) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- халыкны элемтә хезмәте белән тәэмин итүгә шартлар тудыруны тәэмин итә;

- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

4) авыл хуҗалыгын һәм эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүе үсешенә ярдәм итә һәм кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше өчен шартлар тудыра;

5) торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм халыкка башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәт күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- халыкның ялын оештыру өчен һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерүгә шартлар тәэмин итә, Җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су чыгару, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә, үз вәкаләтләре кысаларында халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

- күмү урыннарын карап тора, ритуаль хезмәтләрне оештыра;

-Җирлекнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан таләпләр куела торган коммуналь инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программаларын эшләп чыгара һәм раслый;

6) төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм ташу буенча эшчәнлеген оештыра;

- Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслый, аларның үтәлүен контрольләүне гамәлгә ашыра, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;

- түбәндәге чараларны үз эченә алган Җирлек территориясен төзекләндерүне тормышка ашыра:

а) гомуми кулланылыштагы территорияләрне карап тоту һәм андый территорияләрдән файдалану тәртибе;

б) фасадларның тышкы күренеше һәм биналарның, корылмаларның киртәләү конструкцияләре;

в) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм кабаттан торгызулар, шул исәптән җир эшләре башкарганнан соң;

г) муниципаль берәмлек территориясен яктыртуны оештыру, биналарның, корылмаларның архитектур яктыртылуын да кертеп;

д) муниципаль берәмлек территориясен яшелләндерүне оештыру, торак пунктлар чикләрендә урнашкан үләнчел үсемлекләр белән капланган газоннарны, чәчәклекләрне һәм башка территорияләрне булдыру, карап тоту, кабаттан торгызу һәм саклау тәртибен кертеп;

е) муниципаль берәмлек территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урамнарның исемен һәм йорт номерларын күрсәткечләр, элмә такталар кую;

ж) балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларны, машина кую урыннарын, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту;

з) җәяүлеләр коммуникацияләре, шул исәптән тротуарлар, аллеялар, юллар, сукмаклар оештыру;

и) муниципаль берәмлек территориясен билгеләнгән территория буйлап инвалидлар һәм халыкның башка аз мобильле төркемнәре бернинди тоткарлыксыз хәрәкәт итә алуын тәэмин итү максатыннан җиһазландыру;

к) муниципаль берәмлек территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда;

л) яңгыр сулары агуын оештыру;

м) җир эшләрен оештыру тәртибе;

н) биналарның, корылмаларның, җир кишәрлекләренең милек ияләре һәм (яки) законлы хуҗаларының (йортлар чикләре буенча җир кишәрлекләре булдырылган яки булдырылмаган күп фатирлы йортларда биналарның милек ияләре һәм (яки) законлы хуҗаларыннан кала) чиктәш территорияләрне карап тоту буенча катнашуын, шул исәптән финанслауда катнашуын;

о) Россия Федерациясе субъекты законнары белән билгеләнгән тәртиптә, чиктәш территорияләрнең чикләрен билгеләү;

п) муниципаль берәмлек территорияләрен бәйрәмчә бизәү;

р) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү буенча чараларны оештыру һәм тормышка ашыруда гражданнарның катнашу тәртибе;

с) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру.

- адреслау объектларына адреслар бирә, адресларны юк итә, үзгәртә, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирә (федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларыннан кала, региональ автомобиль юллары яки муниципальара әһәмияткә, муниципаль районның җирле әһәмияткә ия юллардан кала), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирә, шул исемнәрне үзгәртә, юк итә, дәүләт адреслар реестрында мәгълүмат урнаштыра;

- Җирлек халкының массакүләм ялын оештыруга шартлар тудыра һәм халыкның массакүләм ял урыннарын төзекләндерүне, гражданнарга гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм яр буе полосаларына ирекле керүне тәэмин итүне кертеп оештыра;

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә:

- Җирлек территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актларын үтәүне, гражданнарның хокуклары һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

-билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җирле үзидарә хокукларын бозган актларына шикаять бирә;

-муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, Җирлек депутатын чакырту буенча тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрүне, Җирлек чикләрен үзгәртү, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрация һәм пикетларны үткәрү, спорт, тамаша һәм башка массакүләм иҗтимагый чараларны оештыру белән бәйле булган законда каралган чараларны тормышка ашыра;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм итә, халык дружиналары эшчәнлегенә шартлар тудыра;

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итә;

8) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм уздыра;

-милләтара һәм динара килешүне ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятләрен саклау һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптация үтүенә, милләтара (этник) конфликтлар профилактикасына юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

9) оборона, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендә:

- Җирлек территориясендә оборона өлкәсендә, үз компетенциясе чикләрендә, хәрби идарә органнары белән хезмәттәшлек итеп законнар үтәлүне тәэмин итү;

- Башкарма комитет һәм эшчәнлекләре күрсәтелгән органнарның эшчәнлеге белән бәйле булган яки алар карамагында булган оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру, тәэмин итү һәм җитәкчелек итү.

10) Җирлек җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары биргән аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- Җирлек җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен бирелгән матди һәм финанс чараларны дөрес куллануны тәэмин итә һәм хисап алып бара;

- тиешле федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен башкару турында хисап тапшыра;

11) башка вәкаләтләр:

- Җирлек Башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник яки башкача тәэмин итүне тормышка ашыра;

- Җирлекнең архив фондлары формалашуын тәэмин итә;

- әлеге Уставның 6 статьясы 1 бүлеге 4, 9, 18 һәм 19 пунктларында каралган Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрен чишү максатында, Җирлек өчен социаль мөһим эшләрне башкару өчен (шул исәптән кизү тору), җирлектәге гражданнарны ихтыяри рәвештә җәлеп итү карарын кабул итә һәм аларны уздыруны оештыра;

- федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисади элемтәләрне гамәлгә ашыра;

- «Россия Федерациясендә дәүләт-шәхси партнерлыгы, муниципаль-шәхси партнерлык турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 2 бүлеге белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора һәм Россия Федерациясендә муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә гавами партнер буларак чыгыш ясый;

-законнар, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары белән Җирлек Советы һәм Җирлекнең башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә караган вәкаләтләрдән тыш, Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча башка вәкаләтләрне башкара.

2. Башкарма комитет Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә карамаган мәсьәләләрне чишү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- Җирлек музейларын булдыра;

- Җирлектә нотариус булмаганда закон белән каралган нотариаль гамәлләрне башкара;

- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнаша;

- Җирлек территориясендәге җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыруга шартлар тудыра;

- Җирлек территориясендә Россия Федерациясе халыклары милли-мәдәни үсешенә, милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чаралар гамәлгә ашыруда ярдәм итә;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләрне мобилизацион әзерләү буенча чаралар оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

- муниципаль янгыннан саклау хезмәтен булдыра;

- туризмны үстерүгә шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый контрольләүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтә һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык итә;

-инвалидларның иҗтимагый оешмаларына, шулай ук “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, бөтенроссия иҗтимагый инвалидлар берләшмәләре төзегән оешмаларга ярдәм итә;

- торак турында законнар нигезендә социаль кулланудагы торак фонды торак урыннарын найм килешүе буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнарга бирүне оештыра;

- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән чараларны тормышка ашыра;

- "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны тормышка ашыра;

- инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен физик культура һәм спортны, адаптив спортны һәм адаптив физик культураны үстерүгә булышлык итә;

- "Куллануචылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашыра.

3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Җирлек Башкарма комитетының муниципаль контроль өлкәсендә вәкаләтләренә керәләр:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм тормышка ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны тормышка ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Җирлек Советы белән билгеләнгән тәртиптә алып барыла;

2) җирлекнең җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашырылуы буенча вәкаләтләре бирелгән төбәк дәүләт контролен (күзәтчелек) оештыру һәм тормышка ашыру;

3) тиешле эшчәнлек өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру административ регламентларын эшләү, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органнары белән раслана торган типик административ регламентлар нигезендә җирлекнең җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашырылуы буенча вәкаләтләре бирелгән төбәк дәүләт контролен (күзәтчелек) оештыру һәм тормышка ашыру административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) федераль законнар һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

Муниципаль контрольне турыдан-туры тормышка ашыру буенча функцияләр Җирлек Башкарма комитеты органнарына әлеге органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне тормышка ашыру һәм юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерү уздыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә "Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контролен гамәлгә ашырганда хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла

**52 статья. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе**

1. Җирлек Башкарма комитетын җирлек Башкарма комитетының Җитәкчесе җитәкли.

2. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе җирлек җирле үзидарәсенең әлеге вазыйфага контракт буенча билгеләнүче вазыйфаи заты булып тора.

3. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара.

4. Җирлек башкарма комитеты Җитәкчесе, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, эшмәкәрлекк, шулай ук башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуксыз. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса. Җирлекнең Башкарма комитеты Җитәкчесе, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә хокуксыз.

5. Аерым оештыру-күрсәтмә функцияләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарга ия, ул шулай ук җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләрен ул вакытлыча булмаган очракта (авыру яисә ялга китү белән бәйле) яисә үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаган яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта гамәлгә ашыра.

**53 статья. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү тәртибе**

1. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.

Конкурс шартлары, аны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләр, контракт проекты конкурс уздыру көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.

2. Конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны җирлек советы тарафыннан билгеләнә. Җирлекнең конкурс комиссиясе әгъзалары җирлек советы тарафыннан билгеләп куела.

3. Зат җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе өчен контракт шартлары җирлек советы тарафыннан раслана. Федераль закон яисә Татарстан Республикасы законы белән җирлекнең җирле үзидарә органнарына контрактка аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшырган очракта, мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән шартлар кертелә.

5. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән килешү Җирлек Башлыгы тарафыннан төзелә.

**54 статья. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре чоры**

1. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына затны билгеләү турында карар кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш Советы эшли башлаганчы, әмма ике елдан да ким булмаган) төзелә һәм 5 ел тәшкил итә.

2. Җирлек Советының вәкаләтләре чоры тәмамлангач, җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе үз вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә җирлек Башкарма комитетының яңа Җитәкчесе билгеләнгәнчегә кадәр үтәүне дәвам итә.

**55 статья. Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләре**

Башкарма комитет Җитәкчесе:

1) җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге белән берүзе идарә итү принципларында җитәкчелек итә һәм үз компетенциясенә керә торган вәкаләтләрне җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан үтәлүе өчен шәхси җаваплылыкка ия;

2) Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, җирлекнең җирле үзидарәсенең башка органнары һәм башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә җирлекнең Башкарма комитетын тәкъдим итә;

3) җирлек Советы каравына җирлек бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;

4) Җирлек Советы каравына җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;

5) җирлек Советы раславына Башкарма комитет структурасы проектын кертә, җирлек Башлыгы белән килештереп, хезмәткәрләр санының иң чик чиге һәм хезмәткә түләү фонды расланган структура нигезендә җирлек Башкарма комитетының штат расписаниесен раслый;

6) Җирлек башлыгы белән язмача килештереп, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарын билгеләп куя һәм азат итә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирлек Башкарма комитетының башка хезмәткәрләрен билгеләп куя һәм вазыйфасыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чаралары куллана;

7) расланган бюджет нигезендә җирлек чаралары белән эш итә, банк учреждениеләрендә җирлекнең бюджет һәм башка счетларын ача һәм яба, җирлек исеменнән җирлеккә дәгъвалар буенча җавап бирүче вәкиле буларак судта чыгыш ясый:

дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының яисә ведомствога каравы буенча әлеге органнарның вазыйфаи затларының законсыз гамәлләре (гамәл кылмаулары) нәтиҗәсендә, шул исәптән законга яисә башка норматив хокукый актка туры килми торган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары актларын бастыру нәтиҗәсендә физик яисә юридик затка китерелгән зыянны каплау турында;

финанс органы турындагы Нигезләмә нигезендә ведомство буйсынуындагы бюджет учреждениеләренең субсидия җаваплылыгы тәртибендә күрсәтелүче акчалата йөкләмәләре буенча.

8) җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра һәм (яисә) җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итә, аларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота; тиешле законнар нигезендә һәм үтәгәндә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;

9) җирлек Башкарма комитеты компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый актлар, шулай ук җирлек Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

10) елына кимендә бер тапкыр яисә Җирлек Башлыгының, җирлек Советының таләбе буенча җирлек Советына үз эшчәнлеге һәм Башкарма комитет эшчәнлеге турында хисап тапшыра;

11) җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими мәгълүмат бирә, җирлек Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны шәхси кабул итүне гамәлгә ашыра, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

12) дәүләт һәм башка органнарда, җирлекнең Башкарма комитеты исеменнән җирлек мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, судка гариза бирә, ышанычнамәләр тапшыра;

13) законнар, әлеге Устав, җирлек Советы карарлары һәм төзелгән контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**56 статья. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлеме;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 10 өлешенең 11 яисә 11.1 пунктлары нигезендә контрактны өзү;

5) суд тарафыннан хезмәткә сәләтсез яисә хезмәткә сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яки үлгән дип игълан итү;

7) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керүе;

8) даими яшәү урынына Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит ил гражданы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы чит дәүләт органнарына сайланырга, аларга чит дәүләт гражданлыгы алырга йә яшәүгә рөхсәт алу яисә Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил

гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

10) Хәрби хезмәткә чакыру яки аны алыштыра торган альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрелү;

11) җирлек үзгәртеп корылу, шулай ук җирлек бетерелгән очракта;

12) җирлек статусын шәһәр округы белән берләшүгә бәйле рәвештә югалту;

13) җирлек чикләрен яисә шәһәр округы белән җирлек берләшүен үзгәртү нәтиҗәсендә җирлек сайлаучыларының санын 25 процентган артыгракка арттыру;

14) җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү.

2. Башкарма комитет җитәкчесе белән килешү түбәндәге якларның килешүе буенча яисә суд тәртибендә гариза нигезендә өзелергә мөмкин:

1) Җирлек Советы яисә җирлек Башлыгының - контракт шартларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә бозуга бәйле рәвештә, шулай ук законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

2) Татарстан Республикасы Президентының - контракт шартларын җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә, шулай ук законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

3) Башкарма комитет җитәкчесенең - җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары контракты шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

## VI Бүлек. БАШКА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

### 57 статья. Җирлекнең Ревизия комиссиясе

1. Җирлекнең Ревизия комиссиясе даими гамәлдәге тышкы дәүләт финанс контроле органы булып тора һәм Җирлек Советы тарафыннан оештырыла.

2. Җирлекнең Ревизия комиссиясе рәистән һәм ике аудитордан тора.

Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыру һәм эшчәнлеге тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Федераль законнар билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыруны һәм эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

3. Җирлек Советы Биектау муниципаль район Советы белән Биектау муниципаль районы Контроль-хисап палатасына тышкы муниципаль финанс

контролен гамәлгә ашыру буенча Җирлекнең Ревизия комиссиясе вәкаләтләрен бирү турында килешү төзергә хокуклы.

**58 статья. Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты һәм Җирлекнең башка җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге нигезләре**

1. Әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү нигезендә Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы һәм Җирлек Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль башкаралар.

2. Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты законнар, әлеге Устав нигезендә билгеләнгән формаларда Җирлекнең икътисади һәм социаль үсеш процесслары белән нәтиҗәле идарә итү һәм аның халкы мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләү максатыннан, үзара хезмәттәшлек итәргә тиеш.

3. Җирлек Советы һәм Җирлек Башкарма комитеты бер берсенә кабул ителгән хокукый документларны имзалаган көннән җиде көн эчендә юллыйлар.

4. Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы җирлек Башкарма комитеты Җитәчесенә җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенең, җирлек Башкарма комитетының башка вазыйфаи затларының хокукый актларын кабул итү, кире кагу, үзгәртү турында тәкъдим итәргә, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

5. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе Җирлек Советына, Җирлек Башлыгына җирлек Советының, Җирлек Башлыгының хокукый актларын кабул итү, кире кагу, үзгәртү турында тәкъдим итәргә, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

6. Җирлек Башлыгы җирлек Советы Башкарма комитеты Җитәкчесенә җирлек Советы эшенең планнарын һәм җирлек Советы карарлары проектларын җирлек Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

7. Җирлек Советы һәм аның органнары, җирлек Башлыгы үткәрә торган утырышларда киңәш бирү тавышы хокукына ия җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасары яисә алар вәкаләт биргән затлар катнашырга хокуклы. Җирлек Башкарма комитетының вазыйфаи затларыңҗирлек Советы утырышларында язма чакыру булганда катнашуы мәҗбүри.

8. Җирлек башкарма комитеты Җитәкчесе үткәрә торган утырышларда җирлек Башлыгы, җирлек Советы депутатлары катнашырга хокуклы.

9. Җирлекнең башка җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнеше тәртибе Җирлек Советы тарафыннан билгеләнергә мөмкин.

**59 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында бәхәсне хәл итү**

Җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедураларын уздыру юлы белән яки суд тәртибендә хәл ителә.

## VII Бүлек. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

**60 статья. Җирлекнең сайлау комиссиясе**

1. Җирлек сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, Җирлек

башлыгын чакыртып алу, Җирлекнең чикләрен үзгәртү, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны оештыра.

2. Җирлек сайлау комиссиясе Җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган булып тора.

3. Җирлек Сайлау комиссиясе Җирлек Советы тарафыннан "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә билгеләнгән тәртиптә булдырыла.

4. Җирлекнең сайлау комиссиясенең вәкаләтләре срогы биш елны тәшкил итә.

5. Җирлек сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 10 әгъзадан оештырыла.

6. Җирлек сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Җирлек бюджетында, Россия Федерациясе бюджет чыгымнары классификациясе нигезендә, аерым юл белән карала.

7. Җирлек сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән җайга салына. Җирлек Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча Җирлек сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

## VIII Глава. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮ

### 61 статья. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт – хезмәт шартнамәсе (контракт) төзү юлы белән муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган гражданнарның һөнәри эшчәнлеге

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән раслана торган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәтне финанслау Җирлек бюджеты чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

4. Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнар муниципаль хезмәткә тигез керү мөмкинлегенә һәм аны узуга җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка тигез шартларга ия.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы законы белән муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә билгеләнә торган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Вазыйфаи бурычларны үтәүгә кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге

өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе белән шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

**62 статья. Муниципаль хезмәт вазыйфасы**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – әлеге Устав нигезендә җирле үзидарә органындагы, Җирлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында җирле үзидарә органының, җирлек Сайлау комиссиясенең, яисә муниципаль вазыйфа биләүче затның вәкаләтләре башкарылуын тәэмин итү буенча билгеләнгән йөкләмәләр белән барлыкка килгән вазыйфа.

**63 статья. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат, муниципаль хезмәткәр**

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып авыл җирлеге Башлыгы, җирлек Советы депутаты, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган хәлиткеч тавыш хокукына ия муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе, секретаре, әгъзасы торалар.

2. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча Җирлек бюджет акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата түләүгә бурычларын башкаручы граждан муниципаль хезмәткәр булып тора.

3. Җирле үзидарә органнары, Җирлек сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкармыйлар һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормыйлар.

**64 статья. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфалары буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, хезмәт вазыйфаларын башкару сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча күтәрелү шартлары белән танышырга;

2) хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәк булган оештыру-техник чараларны тәэмин итүгә;

3) хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турында закон һәм хезмәт килешүе белән (контракт) туры китереп хезмәткә түләүгә һәм башка түләүләргә;

4) эш (хезмәт) вакытының тиешле дәвамлылыгын көйләү белән тәэмин ителә торган ялга, ял көннәре һәм бәйрәм көннәренә, шулай ук еллык түләүле ялга;

5) билгеләнгән тәртиптә хезмәттәге вазыйфаларын башкару өчен кирәк булган материалларны һәм мәгълүматларны алырга, шулай ук җирле үзидарә органы һәм Җирлек Сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәрен кертүгә;

6) үз инициативасы буенча вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасына конкурста катнашырга;

7) муниципаль хокук акты нигезендә Җирлек бюджеты хисабына өстәмә һөнәри белем алырга;

8) үзенең шәхси мәгълүматларын сакларга;

9) үзенең шәхси эшенең бөтен материаллары белән, һөнәри эшчәнлеге турында фикерләр һәм башка документлар белән аларны шәхси эшенә керткәнче танышып чыгарга, шулай ук үзенең язмача аңлатмаларын шәхси эшенә теркәргә;

10) һөнәри союзлар оештыру хокукын кертеп, иҗтимагый-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрне, үзенең хокукларын яклау өчен оешырга;

11) хезмәт законнары нигезендә шәхси хезмәт бәхәсләрен карап тикшерергә, муниципаль хезмәттә үзенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга, алар бозылган очракта, судка шикаять бирергә;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә, пенсия белән тәэмин итүгә.

2. Муниципаль хезмәткәр, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрдән гайре, яллаучы вәкиленә (эш бирүче) алдан язма рәвештә кисәтеп, башка түләүле эшне башкарырга хокуклы, әгәр бу мәнфәгатьләр конфликтына китермәсә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаса.

3. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасының законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларны башкару;

3) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә расасына, милләтенә, теленә, дингә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе, вазыйфаи инструкция кагыйдәләрен, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларны тиешенчә башкару өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә яисә аларның намусына һәм абруена кагылган белешмәләрне фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль, шул исәптән аңа хезмәт вазыйфаларын башкару өчен бирелгән милекне сакларга;

8) Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә үзе һәм үзенең гаилә әгъзалары турында мәгълүматны тапшырырга;

9) яллаучыга (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында яки чит ил дәүләте гражданлыгын алган көнне чит ил дәүләте гражданлыгын алу турында хәбәр итәргә;

10) федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне сакларга, йөкләмәләрен үтәргә, тыюларны бозмаска;

11) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә язма рәвештә хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау чараларын күрергә.

4. Муниципаль хезмәткәр үзенә бирелгән хокуксыз йөкләмәне үтәргә хаксыз. Тиешле җитәкчедән, муниципаль хезмәткәр фикеренчә, хокуксыз йөкләмә бирелгәндә, муниципаль хезмәткәр, йөкләмә биргән җитәкчегә, әлеге йөкләмәне үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезләмәләре күрсәтелеп, әлеге йөкләмәнең хокуксызлыгын нигезләүне язма рәвештә тапшырырга тиеш. Әлеге йөкләмә җитәкче тарафыннан язма рәвештә расланган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Муниципаль хезмәткәрнең хокуксыз йөкләмәсен үтәгән очракта һәм әлеге йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

**65 статья. Муниципаль хезмәткәргә бирелгән гарантияләр**

1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләр бирелә:

1) вазыйфа инструкциясе нигезендәаның хезмәт вазыйфаларын башкаруын тәэмин итә торган эш шартлары;

2) вакытында һәм тулы күләмдә хезмәт хакын алуга хокук;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән тәэмин ителгән ял, ял көннәре һәм бәйрәм көннәре бирелүгә, шулай ук еллык түләүле ялга хокук;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаиләсенә, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү;

5) муниципаль хезмәткәрне тиешле еллар хезмәт иткән өчен һәм инвалидлык очрагында пенсия белән тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәр үзенең вазыйфасын башкарганда үлгән очракта, аның гаиләсен пенсия белән тәэмин итү;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерү очрагына мәҗбүри дәүләт иминләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узганда яисә аны туктатканнан соң авыру очрагында яисә хезмәткә сәләтне югалткан, әмма ул вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән очракта, мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе;

8) федераль законнарда каралган очракларда, тәртиптә һәм шартларда, вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларына карата көч кулланудан, янаулардан һәм башка хокукый булмаган гамәлләрдән яклау.

2. Җирле үзидарә органы, Җирлек Сайлау комиссиясе бетерелүгә яки җирле үзидарә органы, Җирлек Сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма бетерелү белән яки оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле аны азат иткән очракта муниципаль хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Муниципаль хезмәткәрләргә Татарстан Республикасы законнары белән өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.

**66 статья. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы**

1. Дисциплинар гамәл кылган өчен - муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңа йөкләнгән хезмәт бурычлары аның гаебе белән үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән өчен - яллаучы (эш бирүче) вәкиле түбәндәге дисциплинар чаралар кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә;

3) тиешле нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат итү.

2. Дисциплинар ярамаган гамәл кылган муниципаль хезмәткәр, аның дисциплинар җаваплылыгы турында мәсьәлә хәл ителгәнгә кадәр (ләкин бер айдан да артмаган вакытка), акчалата түләүне саклап вакытлыча хезмәт вазыйфаларын башкарудан азат ителергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне хезмәт вазыйфаларын башкарудан азат итү бу очракта муниципаль хокук акты белән башкарыла.

3. Дисциплинар җаваплылык куллану һәм кире алу тәртибе хезмәт турында законнар белән билгеләнә.

## IX Бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАНЛЫК-ХОКУК ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

**67 статья. Җирлекнең юридик зат хокукына ия булган җирле үзидарә органнары**

1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокукы Җирлек Советына һәм Җирлек Башкарма комитетына бирелә.

2. Җирлек Советы карары буенча Җирлек Башкарма комитеты структурасы нигезендә, юридик зат хокукы Җирлек Башкарма комитетының башка органнарына бирелә ала.

**68 статья. Юридик зат буларак Җирлекнең җирле үзидарә органнары**

1. Җирлек исеменнән Җирлек башлыгы мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар алырга һәм гамәлгә ашырырга, ышанычнамәсез судта чыгыш ясарга мөмкин.

2. Юридик зат хокуклары бирелгән Җирлекнең җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениеләре була һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар буларак дәүләт теркәве узарга тиеш.

**69 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарын финанслау**

Җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген финанс тәэмин итүе бары тик Җирлек бюджетының үзенең кереме хисабына гына гамәлгә ашырыла.

## X Бүлек. ҖИРЛЕК БАШЛЫГЫ ҺӘМ ҖИРЛЕКНЕҢ БАШКА ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА БИРЕЛӘ ТОРГАН СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ТӨР ГАРАНТИЯЛӘР

**70 статья. Җирлек Башлыгы һәм Җирлекнең башка вазыйфаи затларына бирелә торган социаль һәм башка төр гарантияләр**

Җирлек Башлыгының һәм Җирлекнең башка вазыйфаи затларының социаль һәм башка гарантияләре «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Җирлек Советы карарлары нигезендә билгеләнә.

**71 статья. Җирлек Советы депутаты һәм башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка төр гарантияләре**

1. Азат ителмәгән нигездә эшләүче Җирлек Советы депутатына Җирлек Советы һәм аның органнары утырышларында катнашу, Җирлек Советы йөкләмәләрен үтәү чорында, гамәлдәге законнар нигезендә акчалата компенсация һәм башка төр түләүләр түләнә.

2. Азат ителмәгән нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Җирлек Башлыгы урынбасарына Җирлек Башлыгы вазыйфаларын башкарган вакытта әлеге Устав белән каралган очракларда, Җирлек башлыгының айлык акчалата бүләкләвенең 90%ы күләмендә бүләкләү түләнелә.

3. Җирлекнең Ревизия комиссиясе һәм Сайлау комиссиясе әгъзаларына законнар, Җирлек Советы карарлары нигезендә, бу органнарның эшендә катнашкан вакытта акчалата түләү каралган.

**72 статья. Җирлек Башлыгы, Җирлек Советы депутатларының кагылгысызлыгы гарантияләре**

1. Җирлек Советы депутатларының, шул исәптән Җирлек Башлыгының, аларны җинаять яисә административ җаваплылыкка җәлеп иткәндә, тоткарлаганда, кулга алганда, тентүдә, сорау алганда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылуда, шулай ук Җирлек Советы депутатларына карата алар биләгән торак урынын һәм (яисә) хезмәт урынын, багажын, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларын, язышуларын, алар кулланган элемтә чараларын, документларын тикшерү буенча оператив-эзләнү чаралары үткәргәндә, хокуклары гарантияләре федераль законнар белән билгеләнә.

2. Федераль закон нигезендә Җирлек Советы депутаты әйтелгән фикер, тавыш биргәндә белдерелгән позиция һәм аның статусына туры килә торган башка гамәлләр, шул исәптән аның вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң, җинаять яки административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә федераль законда алар өчен җаваплылык каралган Җирлек Советы депутаты тарафыннан җибәрелгән халык алдында кимсетүләр, яла ягу яисә башка хокук бозулар очракларына кагылмый.

## XI Бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

**73 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары җаваплылыгы**

Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары Җирлек халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында федераль законнар нигезендә җаваплылык тота.

**74 статья. Җирле үзидарә органнарының, Җирлек Советы депутатларының Җирлек халкы алдында җаваплылыгы**

1. Җирле үзидарә органнарының Җирлек халкы алдында җаваплылыгы, федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә килеп туа.

2. Җирлек Советы депутатларының, шул исәптән Җирлек Башлыгының Җирлек халкы алдында җаваплылыгы тиешле депутатның аны сайлап куйган Җирлек халкы ышанычын югалткач килеп туа.

3. Җирлек халкы ышанычын югалткан Җирлек Советы депутаты, шул исәптән Җирлек Башлыгы әлеге Уставның 14 статьясында каралган очракларда һәм тәртиптә кире чакыртып алынырга мөмкин.

**75 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затларының дәүләт алдында җаваплылыгы**

1. Федераль законнар нигезендә Җирлек Советының, Җирлек Башлыгының дәүләт алдында җаваплылыгы, алар тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Уставы бозылган очракта, шулай ук җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләре үтәлмәгән очракта тиешле суд карары нигезендә туа.

2. Җирлек Советын тарату, Җирлек Башлыгының вазыйфасыннан баш тартуы һәм отставкага чыгарылуы нигезләре һәм тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә.

**76 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм үзидарә органнары вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы**

Җирле үзидарә органнарының һәм үзидарә органнары вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә килеп туа.

**77 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм үзидарә органнарының вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмаулары), гражданнарның турыдан-туры үз теләген белдерү юлы белән кабул ителгән карарларны судка шикаять итү**

Җирле үзидарә органнарының һәм үзидарә органнарының вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары), гражданнарның турыдан-туры үз теләген белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар судка яки арбитраж судка, законнар белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителергә мөмкин.

**78 статья. Ышанычны югалтуга бәйле муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән чыгару (вазыйфадан азат итү)**

1. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә, түбәндәге очракларда ышанычны югалту сәбәпле азат ителергә тиеш (вазыйфадан азат ителү):

1) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыкканда зат тарафыннан, конфликтның бер ягы буларак, аны булдырмый калу һәм хәл итү буенча чаралар күрелмәү;

2) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яки белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру;

3) затның түләүле нигездә коммерцияле оешманың идарә органнарында эшчәнлек алып баруы, федераль законнарда каралган очраклардан кала;

4) зат тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару;

5) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, затның идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керүе.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат ышанычын югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат, аның буйсынуындагы зат конфликтның бер ягы буларак, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чараларын күрмәгәндә.

3. Коррупциячел хокук бозу кылган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза куллану турында белешмәләр, ул тиешле вазыйфаны биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.

## XII Бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 79 статья. Җирлекнең муниципаль хокукый актлар системасы

1. Җирлекнең муниципаль хокукый актлар системасына керәләр:

1) Җирлек Уставы, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар;

2) Җирлек Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

3) Җирлек Башлыгының, Җирлек Башкарма комитетының, башка җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затларының әлеге Устав белән каралган хокукый актлары.

2. Җирле референдумда кабул ителгән Устав һәм хокукый актлар итеп рәсмиләштерелгән карарлар муниципаль хокук актлар системасында югары юридик көчкә ия булган актлар булып тора, туры көчкә ия һәм Җирлекнең бөтен территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокук актлары әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокук актларына каршы килергә тиеш түгел.

3. Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары һәм органнары кабул иткән муниципаль хокук актлары Җирлекнең бөтен территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешмалар җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

4. Муниципаль хокукый актлар юкка чыгарылырга яисә аларның гамәлдә булуы муниципаль хокукый актны гамәлдән чыгару яисә туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан, мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар бетерелгән очракта яки күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның - җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта, муниципаль хокукый актның гамәлдә булуын туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый актны, шулай ук суд тарафыннан кабул итү (бастырып чыгару) кертелгән, ә җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә - Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы) тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

5. Норматив характерда булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында законнар нигезендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең тиешле күрсәтмәсе алынган очракта кичекмәстән туктатылып тора. Бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше турында җирле үзидарәнең башкарма-күрсәтмә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көн эчендә, ә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына алар карар кабул иткән көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

**80 статья. Гражданнарның туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар**

1. Җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне турыдан-туры Җирлек халкы тарафыннан чишү җирле референдумда белдерелгән гражданнарның туры ихтыяр белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр җирлектә яшәүчеләрне турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен муниципаль норматив хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) өстәмә таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) кергән җирлекнең җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле муниципаль норматив хокукый актны

әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу Җирлек Башлыгын чакыртып алу яки Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

**81 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокук актларының төрләре**

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары аларга йөкләнгән вәкаләтләрне башкарганда түбәндәге муниципаль хокукый актларны чыгаралар:

1) Җирлек Советы – Җирлек Советының карарлары;

2) Җирлек Башлыгы - Җирлек Башлыгы карарлары һәм боерыклары, Җирлек Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары.

2. Җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затлары үзләренең статусларын билгеләүче әлеге Устав, башка муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыклар чыгара.

**82 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү**

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары Җирлек Башлыгы, Җирлек Советы депутатлары, Җирлек җирле үзидарәсенең башка сайланулы органнары, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, Биектау районы прокуроры, шулай ук аны алып бару мәсьәләләре буенча Җирлекнең Ревизион комиссиясе тарафыннан кертелергә мөмкин

2. Биектау муниципаль районы прокуроры үз вәкаләтләрен тормышка ашырган вакытта гамәлдә булган муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерергә кирәклеге билгеләнгәндә, муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, юкка чыгару яки кабул итү турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе һәм аларга беркетелә торган документларның исемлеге һәм формасы Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы Регламенты нигезендә билгеләнәләр.

**83 статья. Җирлек Советының хокукый актлары**

1. Үз компетенциясенә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав керткән мәсьәләләр буенча Җирлек Советы Җирлек территориясендә башкару өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган карарлар, Җирлек Башлыгын отставкага чыгару турында карар, шулай ук Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру һәм аның компетенциясенә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав тарафыннан кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

2. Җирлек территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган Җирлек Советы карарлары, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм бетерүне, җирлек бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Җирлек Советы карарлары Җирлек Советы каравына бары тик Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе булып торучы Җирлек Башлыгы инициативасы яисә аның бәяләмәсе булганда гына кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән бәяләмә Җирлек Башкарма комитетына карар проекты тәкъдим ителгән көннән алып утыз көн эчендә Җирлек Советына тапшырыла.

4. Җирлек Советы карарлары Җирлек Башлыгы тарафыннан аларны кабул иткәннән соң өч көн эчендә имзалана һәм әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

### 84 статья. Җирлек Башлыгының хокукый актлары

Җирлек Башлыгы законнарда, әлеге Уставта, Җирлек Советы карарларында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча, шулай ук әлеге Устав вәкаләтләренә кертелгән башка мәсьәләләр буенча «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә карар һәм күрсәтмәләр чыгара.

Җирлек башлыгы федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта, Җирлек Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча Җирлек Башкарма комитеты карарларын, шулай ук Җирлек Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәсен чыгара.

### 85 статья. Җирлек Башкарма комитеты хокукый актлары

1. Җирлек Башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта, Җирлек Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башкарма комитетның карарларын һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр, шулай ук Җирлек башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләрен чыгара.

2. Башкарма комитет карарлары һәм күрсәтмәләре, әгәр башка тәртип законнарда, әлеге Уставта яисә карар (боерык) белән билгеләнмәгән булса, аларны имзалаган көннән үз көченә керә.

### 86 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр башкасы карарның үзе тарафыннан билгеләнмәгән булса, Җирлек Башлыгы имзалаган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Салымнар һәм җыемнар турында Җирлек Советының норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Советының Уставны кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарлары федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек Башлыгының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары имзаланган көннән үз көченә керә, әгәр актларның үзләре белән башкасы билгеләнмәгән булса.

3. Оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау ст. т/юл бистәсе, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмати стендта һәм Биектау муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://ykava-tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, имзалау датасы (Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен - шулай ук аны Җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актны имзалаган вазыйфаи зат исеме, мөһер булырга тиеш.

5. Җирлекнең бюджеты турында, аның үтәлеше турында хисап хакында, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турында карарлар, Җирлек Советы Регламенты, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар, аларны имзалаган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш, моңа федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль норматив хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре керми.

6. Муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында, Җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләсе, Җирлек башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау турындагынорматив булмаган хокукый актлар һәм законнар нигезендә башка актлар мәҗбүри рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми басылып чыгуы (халыкка җиткерелүе) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган органнар яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

8. Басып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәгеләр белән гамәлгә ашырыла:

-хокукый акт текстын яки хокукый акт проектын "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштыру

-хокукый акт текстын Җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашкан урыны Җирлек Советы тарафыннан раслана һәм Җирлек халкы

муниципаль хокукый акт тексты белән бернинди тоткарлыксыз таныша алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру.

- Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында хокукый актны урнаштыру (http://pravo-minjust.ru, http://хокук-минюст.рф Теркәү челтәр басмасы буларак теркәлү: Эл № ФС77-72471 05.03.2018).

9. Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасы чыгу датасы яки тиешле акт халыкка җиткерү датасы турында белешмәләр актны тарату (өләшү) башлану датасына яисә аны мәгълүмати стендта урнаштыру датасына туры килергә тиеш.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 87 статья. Муниципаль хокукый актларны юкка чыгару һәм аларны гамәлдән чыгару

1. Муниципаль хокукый актлар юкка чыгарылырга яисә аларның гамәлдә булуы тиешле муниципаль хокукый акт кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан, мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар бетерелгән очракта, яки күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның - җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта, вәкаләтләренә муниципаль хокукый актның гамәлдә булуын туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) кертелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары, шулай ук суд тарафыннан; ә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә - Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы) тарафыннан (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы) үзгәртелергә мөмкин.

Норматив характерда булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында законнар нигезендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең тиешле күрсәтмәсе алынган очракта кичекмәстән туктатылып тора. Бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше турында җирле үзидарәнең башкарма-күрсәтмә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көн эчендә, ә җирле

үзидарәнең вәкиллекле органнарына алар карар кабул иткән көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

2. Суд карары нигезендә муниципаль берәмлек статусын билгеләү турында Татарстан Республикасының яңа законы үз көченә кергәнче гамәлдә булмаган муниципаль берәмлек статусын билгеләү хакында Татарстан Республикасы законы карары буенча закон көченә кергәнче кабул ителгән күрсәтелгән муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый актларын суд тәртибендә гамәлгә яраксыз дип тану яисә муниципаль хокукый актлар күрсәткечләрен гамәлдән чыгару өчен нигез була алмый.

## XIII Бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ НИГЕЗЕ

### Статья 88. Җирлекнең муниципаль мөлкәте

1. Җирлекнең җирле үзидарәсе икътисадый нигезен Җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт, Җирлек бюджеты акчалары, шулай ук Җирлекнең мөлкәти хокуклары тәшкил итә.

2. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) Җирлек җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә үзләренә тапшырылган җирлекнең җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм җирлек учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеген Җирлек Советы норматив хокукый актлары нигезендә тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына аларны хәл итү федераль законнар белән бирелгән һәм Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1, 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән мөлкәтнең профиле үзгәртелергә (максатчан билгеләнешен үзгәртергә) яисә читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.

**89 статья. Җирлекнең муниципаль мөлкәтенә ия булу, куллану һәм идарә итү**

1. Җирле үзидарә органнары Җирлек исеменнән Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль ия булалар, файдаланалар һәм аның белән эш итәләр.

2. Җирлек муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә Совет карары белән билгеләнә.

3. Муниципаль мөлкәтне файдаланудан һәм хосусыйлаштырудан керемнәр Җирлек бюджетына керә.

4. Җирле үзидарә органнары Совет раслаган тәртип нигезендә муниципаль мөлкәтне Җирлекнең физик һәм юридик затларына, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына) һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә башка килешүләр башкарырга, читләштерергә, гамәлгә ашырырга хокуклы.

5. Җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәт реестрларын Россия Федерациясе Хөкүмәте, федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә алып баралар.

**90 статья. Муниципаль предприятие, учреждение һәм хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Җирлек муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, үзгәртеп кора һәм бетерә, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара оешмалар төзүдә катнаша ала. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Җирле үзидарә органы муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең эшчәнлеге максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый.

3. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы законнар нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләрен үз вазыйфасына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеге турындагы хисапларны әлеге статьяда каралган тәртиптә тыңлый.

Муниципаль унитар предприятиеләр, җирлек учреждениеләре җитәкчеләре Россия Федерациясенең хезмәт турындагы законнары һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә вазыйфага шартнамә нигезендә билгеләнеп куела.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек исеменнән Җирлек муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидиар җавап бирә һәм аларны үтәүне Россия Федерациясе Гражданнар кодексында билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә.

5. Җирлекнең муниципаль учреждениеләре җирле үзидарә органына үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында һәм үзләренә беркетелгән Җирлек муниципаль мөлкәтеннән файдалану турында җирле үзидарә органы билгеләгән тәртиптә төзелә

һәм раслана торган, һәм башкарма хакимиятнең бюджет, салым, иминият, валюта, банк эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль органы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә хисапларны тапшыра.

Хисап чоры тәмамланганнан соң, Җирлекнең муниципаль предприятиеләре җирле үзидарә органына бухгалтерлык хисабы һәм исемлеге җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә торган башка документлар тапшыра.

6. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләре Җирлек Советы алдында эшчәнлек нәтиҗәләре турында елга кимендә бер тапкыр хисап тоталар.

7. Җирле үзидарә органы таләбе буенча муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләре ел саен, еллык хисап бирү белән бергә, муниципаль предприятиенең яисә учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турында аңлатма язуы тапшырырга тиеш.

8. Вакытлыча мәҗбүри хисаплылыктан тыш, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләре үзләре җитәкләгән муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең эшчәнлекләре турында Җирлекнең җирле үзидарә органнары соратулары буенча шул сорауларда билгеләнгән күләмнәрдә һәм срокларда мәгълүмат һәм хисаплар бирергә тиеш. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы билгеләгән очракларда Җирлек муниципаль предприятиесенең бухгалтерлык исәп-хисабы бәйсез аудитор тарафыннан ел саен мәҗбүри аудиторлык тикшерүе узарга тиеш.

Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләре бирелгән хисаплылыкның дөреслеге һәм үз вакытында башкарылуы өчен шәхси җаваплы булалар.

**91 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятие, учреждение һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре**

Җирлекнең җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, законнарда башкасы билгеләнмәсә, шартнамә нигезендә төзелә.

## XIV Бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

**92 статья. Җирлек бюджеты**

1. Җирлек үз бюджетына ия.

2. Җирлек бюджеты Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый акты рәвешендә әзерләнә һәм раслана.

3. Җирлек бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга юллана торган керемнәр, һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләр, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Җирлек бюджеты тиешле чыгымнары аерым карала.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең федераль законнарында һәм алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисаплар тапшыра.

**93 статья. Җирлектә бюджет процессы**

1. Җирлек бюджетының проектын төзү һәм карау, Җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексында каралган таләпләрне үтәп, Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек бюджеты прокты, Җирлекнең бюджетын раслау турында Җирлек Советы карары, аның үтәлеше турында еллык хисап, квартал саен бирелә торган Җирлек бюджеты үтәлеше турында һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре саны турында аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар күрсәтелеп белешмәләр, Җирлек торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaykaya.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Җирле салымнар турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында Җирлек Советы муниципаль норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен үзгәртүгә китерә торган, чираттагы финанс елында һәм план чорыннан үз көченә керә торган Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый актлары чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турындагы карар проекты Җирлек Советына кертелергә 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Җирлек бюджеты проекты өч елга төзелә һәм раслана (чираттагы финанс елы һәм план чоры).

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проекты Җирлекнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проекты, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә, Җирлекнең Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Җыенына Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

- Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;

- Җирлек бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;
- социаль-икътисади үсеше турында фаразлау (прогноз);
- озак срокка бюджет фаразлавы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрүе проекты);
- муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, муниципаль программалар үзгәрүе проектлары).

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты керә торган бюджетның төп характеристикалары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законнарында, Җирлек Советының муниципаль хокукый актларында (бюджет турындагы карардан тыш) билгеләнгән башка күрсәткечләр булырга тиеш.

9. Җирлек бюджеты турында карар белән расланалар:
- Җирлек бюджеты керемнәренең төп администраторлары исемлеге;
- Җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеге;
- чыгымнарның төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләренә) яки чыгымнарның төрләре бюджетлар чыгымнары классификациясенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм (яки) эшчәнлекнең программада каралмаган юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре), шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Җирлек Советы муниципаль хокукый акты нигезендә билгеләнгән очракларда бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;
- гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;
- чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет расланган очракта план чорының беренче елына шартлы раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнешле Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына бюджет чыгымнары гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнешле Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);
- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;
- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче (чираттагы финанс елы) елның 1 январена торышы буенча муниципаль эчке бурычның югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның югары чиге;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, Җирлек Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән Җирлек бюджетының башка күрсәткечләре.

10. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проекты расланган бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү һәм бюджет проектының икенче ел план чорының параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проекты план чорының расланган бюджеты күрсәткечләрен төгәлләштерә һәм төзелә торган бюджетның план чорының икенче елы күрсәткечләрен раслый.

11. Җирлек Советына бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта түбәндәгеләр тапшырыла:

- Җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең чираттагы финанс елына һәм план чорына төп юнәлешләре;

- агымдагы финанс елның узган чорындагы Җирлекнең социаль-икътисадый үсешенә алдан йомгаклар ясау һәм агымдагы финанс елы өчен Җирлекнең социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган нәтиҗәләре;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлекнең социаль-икътисадый үсешен фаразлау;

- Җирлек бюджетының төп характеристикаларын чираттагы финанс елына һәм план чорына фаразлау (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы);

- Җирлек бюджеты проектына аңлатма язуы;

- бюджетара трансфертларны бүлүнең методикалары (методикалары проектлары) һәм исәпләре;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварена муниципаль эчке бурычның югары чиге;

- агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

- Җирлек Советы, суд системасы органнары, Җирлекнең Ревизия комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата Җирлекнең Башкарма комитеты белән каршылыклар барлыкка килгән очракта тапшырыла торган;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав тарафыннан билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Муниципаль программалар буенча һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү бюджет турындагы карар белән расланган очракта, Җирлек бюджеты турындагы карар проектына муниципаль программалар паспорты (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары) тапшырыла.

Җирлек бюджеты турында карар проектында бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта булмаса, бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта Җирлек бюджеты турындагы карар проектына аңлатма язуы кушымталары составына кертелә.

12. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проектын төзү Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар, алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Җирлекнең Башкарма комитеты чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проектын агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Җирлек Советы каравына кертә.

14. Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнгән Җирлек бюджеты турындагы карар проектын карау һәм раслау тәртибе чираттагы финанс елының 1 январеннән бюджет турындагы карар үз көченә керүне, шулай ук әлеге карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә күрсәткечләрне һәм характеристикаларны (кушымталарны) раслауны күздә тотарга тиеш.

15. Җирлек бюджеты турындагы карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) Җирлек бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса, финанс елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Җирлек бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

16. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Җирлек бюджетының баланслылыгын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, муниципаль бурыч дефициты, күләме һәм структурасы, Җирлекнең бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча билгеләнгән федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарының һәм үтәлешен тәэмин итә.

17. Җирлек бюджеты керемнәре Россия Федерациясе бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә төзелә.

18. Җирлек бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда гамәлгә ашырыла.

19. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга Җирлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру рөхсәт ителми.

20. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

**94 статья. Җирлекнең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**95 статья. Җирлек гражданнарының үзара салым акчасы**

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, гражданнарының саны Җирлек (Җирлек составына керә торган торак пункт) халкының гомуми санының 30 процентыннан артмаган һәм түләүләре күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләреннән тыш, Җирлек (җирлек составына керә торган торак пункт) халкы өчен бертигез дәрәҗәдә билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер мәртәбә түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.

### 96 статья. Җирлекнең муниципаль бурыч алуы (муниципаль бурыч)

1. Җирлек бюджетын финанслау һәм бурыч йөкләмәләрен каплау максатларында Җирлек федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль эчке бурыч алуны гамәлгә ашырырга хокуклы.

Муниципаль бурыч алу дигәндә, гавами-хокукый берәмлек исеменнән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм заемчы буларак гавами-хокукый берәмлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә гавами-хокукый берәмлек бюджетына заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашыру хокукына Җирлек Башкарма комитеты ия.

### 97 статья. Җирлек бюджеты үтәлеше

1. Җирлек бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек бюджеты касса бердәмлеге һәм чыгымнарның бирелгәнлеге нигезендә башкарыла.

3. Җирлек бюджетының үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, Җирлек бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Җирлек бюджетын үтәү Җирлек бюджет язмасы һәм Җирлекнең касса планы нигезендә оештырыла.

### 98 статья. Бюджет хисабы. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап

1. Җирлекнең бюджет хисабы еллык булып тора.

2. Җирлекнең бюджет хисабы Башкарма комитет тарафыннан бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисабы нигезендә төзелә.

3. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Җирлек Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Җирлек Советына тапшырылганчы Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне үз эченә алган һәм Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләргә тиеш.

Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү, федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, Җирлек Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә, Җирлек Советы Ревизия комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек Бюджетының үтәлеше турында, аңа бәяләмәне әзерләү өчен агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча хисап тапшыра. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисабының еллык бюджет эчке тикшерүе күрсәткечләре нигезендә 1 айдан артмаган срокта үткәрелә.

6. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә Җирлек Ревизия комиссиясе тарафыннан Җирлек Советына һәм Җирлек Башкарма комитетына бер үк вакытта җибәрелеп тапшырыла.

7. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан соңга калмыйча, Җирлек Башкарма комитеты Җирлек Советына Җирлек бюджеты үтәлеше турында финанс елы өчен еллык хисап Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап финанс елы, Җирлек бюджетының үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы проектын һәм Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документларны үтәү турында Җирлек Советы карары проектын кушымта белән тапшырырга тиеш.

8. Бюджет үтәлеше турында еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча Җирлек Советы Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисап Җирлек Советы тарафыннан кире кагылган очракта, ул күрсәткечләрне дөрес яисә тулы булмаган чагылдыру фактларын бетерү һәм 1 айдан артмаган срокта кабат тапшыру өчен кайта.

9. Җирлек бюджетының үтәлеше турындагы карар белән, керемнәр, чыгымнарның һәм бюджет кытлыгының гомуми суммасын күрсәтеп, хисап финанс елы өчен Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап раслана.

Хисап финанс елы өчен Җирлек бюджеты үтәлеше турында Җирлек Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Җирлек керемнәре;
- бюджет чыгымнары ведомство структурасы буенча Җирлек бюджеты чыгымнары;
- бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча;
- бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының.

Җирлек бюджетын үтәү турындагы карар белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Җирлек Советы муниципаль хокукый акты нигезендә билгеләнгән Җирлек Бюджеты үтәлеше турында карар өчен башка күрсәткечләр раслана.

**99 статья. Муниципаль финанс контроле**

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче хокукый актлар нигезләрен, физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне, шулай ук бюджеттан чаралар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, беренчел һәм чираттагы финанс контроленә бүленә.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Җирлек Ревизия комиссиясенең контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Җирлек Башкарма комитетының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Алдан тикшерү Җирлек бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларын кисәтү һәм булдырмый калу максатларында гамәлгә ашырыла.

5. Киләсе контроль Җирлек бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча аны үтәүнең законлылыгын, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.

**100 статья. Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисапны әзерләү, карау һәм раслау**

1. Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап (алга таба - хисап) Советның муниципаль хокукый акты проекты рәвешендә эшләнә һәм раслана.

2. Җирлекнең бюджет хисабы тиешле баш администраторларның бюджет акчалары җыелма бюджет хисабы нигезендә Җирлекнең финанс органы тарафыннан төзелә.

Хисап Җирлек Советына Башкарма комитет тарафыннан Советның муниципаль хокукый акты проекты формасында Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган документлар һәм материаллар белән бергә агымдагы елның 1 маеннан соңга калмыйча тапшырыла.

3. Хисапны карый башлаганчы хисапны тышкы тикшерү уздырыла.

4. Хисап Совет тарафыннан билгеләнә торган гавами тыңлауларга кертелә.

5. Совет хисап буенча карарны хисапны тикшерү нәтиҗәләрен алганнан һәм хисапны гавами тыңлауларда караганнан соң карар кабул итә.

6. Хисапны карау нәтиҗәләре буенча Совет Җирлек бюджеты үтәлеше турында карарны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Җирлек бюджеты үтәлеше турында карар кире кагылган очракта, ул дөреслеккә яки тулы булмаган мәгълүматлар булу фактларын бетерү һәм кабат тапшыру өчен бер айдан да артмаган срокка кире кайта.

7. Җирлекнең финанс органы бюджет хисабын Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге финанс органына тапшыра.

**101 статья. Муниципаль бурыч белән идарә итү**

1. Муниципаль бурыч белән идарә итүне Җирлек башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

2. Муниципаль бурыч белән идарә итү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 һәм 111 статьяларында билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

Әгәр җирле бюджетны үтәгәндә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 һәм 111 статьяларында күрсәтелгән чик күрсәткечләр бозылса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы Җирлек муниципаль бурычны реструктуризацияләү максатларында тиешле бурыч йөкләмәләрен кабул итүдән тыш, яңа бурыч йөкләмәләре кабул итәргә хокуксыз.

Җирлек бюджеты турында карар кабул итү этабында Совет һәм Җирлек бюджетын төзү һәм үтәү этабында Җирлекнең финанс органы, шулай ук муниципаль бурыч белән идарә итү барышында үз компетенциясе чикләрендә күрсәтелгән чикләүләрнең үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

3. Җирлекнең финанс органы Җирлек муниципаль бурыч китабын алып бара, аңа Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән белешмәләр кертелә, шулай ук Җирлекнең муниципаль бурыч китабына кертелү тәртибе һәм срогы җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә торган башка мәгълүмат кертелә.

## XV Бүлек. УСТАВНЫ КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ

### 102 статья. Устав проектын әзерләү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1. Устав проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карар проекты Җирлек Советына Җирлек Советы депутатлары, Җирлек Башлыгы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициативалы төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Устав проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен Җирлек Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Устав проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында Җирлек Советы карар проекты, аларны Устав кабул итү турында мәсьәлә каралган көнгә кадәр, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткәнчегә кадәр 30 көннән соңга калмыйча, Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә, Устав проекты буенча тәкъдимнәрне, гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен исәпкә алып, рәсми рәвештә ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау т\юл бистәсе, Советская урамы, 13 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмати стендта, яки “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, яки Татарстан Республикасы законнары

нигезләмәләренә тәңгәл китереп, Уставка әлеге норматив хокукый актлар нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

4. Җирлек Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советының карары буенча Җирлек Советында каралу алдыннан әлеге Устав нигезендә халык алдында тыңлаулар үткәрелә, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлап, бу Уставны әлеге норматив хокукый актлар белән туры китерү максатында үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очрактан кала.

**103 статья. Уставны кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе**

1. Устав проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын карау Җирлек Советы тарафыннан Җирлек Советы Регламенты нигезендә икедән ким булмаган укылышта гамәлгә ашырыла.

2. Устав проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң, күрсәтелгән проект Җирлек Башлыгы тарафыннан Җирлек Советы депутатларына, хокук чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга төзәтмәләр кертү өчен җибәрелә.

3. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесенең күпчелеге тарафыннан кабул ителә.

4. Уставны федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү шушы закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, Җирлек Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә керү датасын, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм гавами тыңлауларда фикер алышу зарурлыгын, гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу, Җирлек Советы утырышларының чиратлылыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.

**104 статья. Уставның, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарның үз көченә керү тәртибе**

1. Устав, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары кабул ителгәннән соң, Җирлек Башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә.

2. Устав, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары, алар дәүләт теркәве узганнан соң, рәсми рәвештә ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл ст. бистәсе, Советская урамы, 13 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы

Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендта яки "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokayagora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча, шулай ук Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында (http://pravominjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәү: Эл № ФС77-72471 05.03.2018) рәсми рәвештә бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм рәсми рәвештә бастырылып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керәләр.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актны яисә килешүне рәсми бастырып чыгару аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче бастырып чыгару булып санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук "Интернет" челтәре басмасыннан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, матбугат басмасында аңа карата күләмле график һәм таблица-кушымталар китерелмәскә мөмкин.

3. Уставка кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү (Уставны федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук вәкаләтләрне үзгәртү, вәкаләтләрнең срогы, Җирлек Башлыгын һәм җирле үзидарәнең башка сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибеннән тыш) Уставка шушы үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында карар кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

4. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә һәм түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) Җирлек Башлыгы имзалаган Җирлек Советы карары;

2) Җирлек Советы кабул иткән һәм Җирлек Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге норматив хокукый актта Җирлек Советының аны кабул итү турында карары реквизитлары куела. Җирлек Советының мондый карарына җирлек Уставына кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр үз көченә керү турында күчеш нигезләмәләре һәм (яки) нормалары куелу рөхсәт ителми.

5. Уставны яңа редакциядә бәян итү Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән кую рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Устав кабул ителә, ә элек гамәлдә булган Устав һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар яңа Устав үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.